КЫЙММӘТЛЕ КУЫШ

Фатирны кайчан алу отышлы?

> 5



«БИШЛЕ» КУЯРЛЫКМЫ?

Татарстанда быелгы уку елы нәтиҗәләре

> 15

ЧУЛПАН ЗАКИРОВА:

«Тәнкыйть битарафлыкка караганда яхшырак»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 73 (28846) | Җомга | 27 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

selet.biz.ru

КЫЙБЛАҢ БАРМЫ?

ИДЕОЛОГИК ТӘРБИЯ ВАКЫТЫ ҖИТТЕ

Хәзерге чор яшьләренә тәнкыйть күп эләгә. Кызганучылар, алар өчен борчылучылар да җитәрлек. Рухи маяклары, терәүләре юк, диләр, «элеккечә» булмауда гаеплиләр. «Элеккечә» ясар өчен, төрле оешма-хәрәкәтләр дә оештырып карыйлар. Тик элек яраганнар хәзергеләргә килешәме икән ул...

> 6

Ишетми калмагыз

Республиканың ЮХИДИ идарәсе башлыгы итеп Рөстәм Гарипов билгеләнде. Идарә хезмәткәрләренә тәкъдим иткәндә Татарстан буенча эчке эшләр министры Артем Хохорин аны яхшы әзерлекле, эшнең барлык нечкәлекләрен белгән җитәкче дип атады.

Рөстәм Гарипов эчке эшләр органнарындагы хезмәтен Чистайда юл-патруль хезмәте инспекторы вазыйфасыннан башлаган. Соңрак Нурлатта һәм Түбән Кама да ЮХИДИ бүлекчәләрен җитәкләгән. Билгеле булганча, идарәнең элекке башлыгы Ленар Габдрахманов Россия Президенты указы белән РФ Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Баш идарәсе башлыгы урынбасары итеп билгеләнде.

Татарстанда Корбан бәйрәме көннәрендә 17 меңгә якын корбан чалу күздә тотыла. Бу хакта Диния нәзарәтенең үзәк ревизия комиссиясе рәисе Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин белдерде. «Халык белән аралашудан соң шул мәгълүм булды: корбанга үстерелгән сарыкларның артуы – 17 мең башка җитүе көтелә. Мөгезле эре терлеккә килсәк, республикада 50–60 башка тулыр, мөгаен. Тәгаен ничек буласын Корбан бәйрәменнән соң күрербез. Әмма күтәрелеш сизелә. Пандемия чорында халык алҗыды, рамазан аенда бик активлашты. Кешеләрнең тормыш кыйммәтләре яхшы якка үзгәрә», – диде Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин. Быел Корбан бәйрәме 9 июльдә булачак.

Быел федераль Сабан туе Ульяновск өлкәсендә узачак. Анда Россиянең төрле почмакларыннан 40 меңнән артыграк кунакның килүе көтелә. Төп бәйрәм чаралары 17–18 июнь көннәрендә Ульяновск шәһәре ипподромында һәм Җиңү паркында узачак. Моннан тыш төбәкнең барлык муниципалитетларында Сабан туе мәйданчыклары оештырылачак. 17 июньдә ипподромда ат спорты ярышлары уза, Татарстанның халык һөнәрчелеге осталары күргәзмәсе эшләячәк. Кичен Татарстан һәм Ульяновск өлкәсе артистлары катнашында бәйрәм концерты башлана. Сабантуй исә 18 июньдә узачак.

Ниһаять, җылыта. Һава температурасы ай буе нормадан 6–9 градуска түбәнрәк торганнан соң, һәркайсыбыз өчен көтеп алынган хәбәр бу. Инде ял көннәрендә үк көндез температура +22 градуска җитәчәк. Татарстан Гидрометеоүзәгеннән хәбәр ителгәнчә, бүген төнлә урыны белән яңгыр, +3...+8 градус җылы. Ял көннәрендә – 28 һәм 29 майда яңгырлы һава торышы сакланачак. Кайбер районнарда секундына 15–20 метр тизлектә көчле җил һәм яшен көтелә. Көндез +16...+22 градус, төнлә +6...+12 градус булачак. Киләсе атна башында – 30 һәм 31 майда, антициклон үтеп керү һәм атмосфера басымы үсү сәбәпле, явым-төшем туктар, температура күтәрелер дип фаразлана: көндез +19...+25, төнлә +7...+13 градус җылы көтелә.

ПРЕЗИДЕНТ ӘЙТТЕ

Владимир Путин Дәүләт Советы президиумы утырышын уздырды. «Без һәрвакыт эшебезне киләчәккә, бер адым алга карап корырга тиеш. Ә өстенлекле төп юнәлешебез – халыкның тормыш сыйфатын һәм иминлеген үстерү», – диде Россия Президенты. Бу җәһәттән нәрсә көтелә?

Хәрбиләргә социаль ярдәм турында

«Хәрби хезмәткәрләргә, бигрәк тә яралануларга, барыннан да бигрәк һәлак булган иптәшләребезнең гаиләләренә социаль ярдәм мәсьәләләрен тиз һәм тулы күләмдә хәл итәргә кирәк. Бу акчалата түләүләргә, премияләргә кагыла», – диде Владимир Путин. Акчаны исәпләгәндә, хәрбиләрнең чит илдә булуы һәм доллар бәясе үзгәрүне дә исәпкә алачаклар.

Инфляция һәм эшсезләр

Владимир Путин, ел башыннан илдәге инфляция дәрәҗәсе 11 проценттан артып китте, дип белдерде. Әмма хәзер ул акрынайган. Ул искәрткәнчә, 2022 ел нәтиҗәләре буенча, бу күрсәткеч 15 проценттан да артмаска тиеш. Ил башлыгы илдәге эшсезлек дәрәҗәсе дә бераз кимегәнен әйтте. Хәзер ул – 4 процент. Артуга юл куймаска кирәк, дип саный Президент.

Пенсия, социаль ярдәм

Владимир Путин, Россиядә минималь хезмәт хакы күләме һәм яшәү минимумы артачак, дип игълан итте. 1 июньнән минималь хезмәт хакы 10 процентка, ягъни аена 13890 сумнан 15278 сумга кадәр артачак. Яшәү минимумы да 10 процентка артыр дип көтелә. Анысы ил буенча 13919 сумга кадәр җитәчәк.

Моңа өстәп, Владимир Путин 1 июньнән эшләмәүче пенсионерларга пенсияләрне 10 процентка арттырырга тәкъдим итте.

Күпбалалы гаиләләргә ярдәм

Россиядә күпбалалы гаилә норма булырга тиеш. Ил башлыгы утырышта шул хакта әйтте. Аның фикеренчә, күпбалалы һәм нык гаилә демографиягә бәйле проблемаларны урап узарга мөмкинлек бирәчәк. Ә ул Россия өчен актуаль кала.

Түбән Камада – бәйрәм

Нефть химиясе сәнәгате – Татарстанның үсеш ноктаtotal ларыннан берсе. Президент Рөстәм Миңнеханов Түбән Кама шәһәрендә Химиклар көнендә ясаган чыгышында шулай дип белдерде.

«Үсеш стратегиясе-2030 буенча, нефть химиясе – республиканың иң мөһим үсеш нокталарыннан берсе. Без шушы юнәлештә барабыз да», – диде Президент. Рөстәм Миңнеханов искә төшереп үткәнчә, хәзерге вакытта нефть химиясе төбәктә җитештерелүче бөтен сәнәгать продукциясенең 40 процентын тәшкил итә. Ул шулай ук республикада тармакның барлык партнерларының ниятләнелгәннәренә ирешәчәгенә ышаныч белдерде. «Сезне бәйрәм белән котлап, илебезнең чәчәк атуын телим! Бирегә сезнең өлешегез гаять зур», – диде Татарстан Президенты, бәйрәмгә җыелган халыкка мөрәҗәгать итеп.

Түбән Камада Рөстәм Миңнеханов Татарстан Хөкүмәте һәм «СИБУР Холдинг» ГАҖ арасында хезмәттәшлек турындагы килешүне гамәлгә ашыру буенча киңәшмәдә дә катнашты. Бирегә «СИБУР» компанияләр төркеменә керүче республика предприятиеләренең узган елгы эш нәтиҗәләре, җитештерү куәтләрен модернизацияләү мәсьәләләре, шулай ук Татарстанда социаль инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру мөмкинлекләре турында фикер алыштылар.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«БЕЗНЕҢ БУРЫЧ – ЭШМӘКӘРЛЕККӘ ТЕЛӘКТӘШЛЕК КҮРСӘТҮ»

Россиядә бизнеска административ басым кимегән. Бу өлкәдә Татарстан хәтта сизелерлек уңышларга ирешкән. 2021 ел нәтиҗәләре буенча, ул алтмышынчы урыннан дүртенчегә үк күтәрелгән. Әлеге күрсәткечләргә, әйтик, штраф салу урынына кисәтү ясау хисабына ирешкәннәр. Шул ук вакытта эшмәкәрләрне борчыган мәсьәләләр дә шактый.

Мәсәлән, микрозаемнар буенча процент ставкаларын Үзәк банкның төп ставкасына бәйләү, җир сатып алу тәртипләренә үзгәрешләр кертелү сәбәпле, бәяләрнең өскә сикерүе һәм башкалар. Россия эшмәкәрләре көнендә бизнес вәкилләре үз гозерләрен республика җитәкчелегенә җиткерә алды.

Эшмәкәрләр белән очрашуда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов аларны бәйрәм белән котлады һәм кече һәм урта бизнесның икътисадта илне һәм республиканы алга этәрүче төп нигез булып торуын әйтте.

– Эшмәкәрләр – безнең нигез. Төп бурычыбыз – көчле урта класс булдыру. Булдыклы һәм эшлекле кешеләр тәвәккәл булу, гамәл кылу һәм алга таба бару сәләтенә ия. Безнең бурыч – әлеге хәрәкәткә теләктәшлек күрсәтү, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Аның фикеренчә, эшмәкәрләргә ярдәм йөзеннән федераль дәрәҗәдә зур эшләр башкарыла. Россиягә каршы кертелгән санкцияләр шартларында кече һәм урта бизнесны үстерүдә әлеге чаралар аеруча актуаль, дип билгеләп узды Президент.

– Әлеге бушлыкны хәл итү өчен планлы эшләр бара, – дип ассызыклады ул.

Президент сүзләрен Стратегик инициативалар агентлыгының төбәк үсеше директоры Александр Смекалин да куәтләде. Ул эшмәкәрләргә ярдәм күрсәтүдә республиканың зур уңышка ирешүен билгеләп узды.

– Эшмәкәр үз тирәсендәге тормышны үзгәртергә сәләтле ихтыяр көченә һәм энергиягә ия. Дөрес, күп нәрсә дәүләт органнары һәм эшмәкәрләрнең үзара мөнәсәбәтенә бәйле. Мондый хезмәттәшлектә нindидер яңа, зур һәм бөек эшләр килеп чыгарга мөмкин. Һәм монда Татарстан әлеге үзара аңлашуны күрсәтә, бөтен илгә үрнәк итеп күрсәтерлек нәтиҗәләргә ирешә, – диде Александр Смекалин.

Билгеле, гадәттә мондый очрашулар вакытында эшмәкәрләр республика, ә кайвакыт хәтта ил җитәкчелегенә дә алар аша борчыган сорауларын җиткереп, уңай чишелеш табарга омтыла. Бу юлы да шулай булды. Ресторан, матурлык салоннары, туризм тармагында уңышлы эшләп килүче эшмәкәр Алсу Кузнецова, мәсәлән, республикада кече һәм урта бизнес субъектларына ташламалы кредит бирү буенча бик күп программалар эшләп килүен әйтеп, микрозаемнар буенча процент ставкаларын Үзәк банкның төп ставкасына бәйләүне сорады.

Бизнесмен ханымның соравына Татарстанның икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов җавап бирде. Аның сүзләренчә, Үзәк банкның директорлар советы карар кабул иткәч, министрлык ставкага төзәтмәләр кертергә әзер.

tatarstan.ru

– Икътисад министрлыгы инде әзер! Нәбиуллина (Үзәк банк рәисе Эльвира Нәбиуллина. – **Авт.**) кире уйламасын дип Ходайдан сорагыз, – диде, уенын-чынын бергә кушып, Рөстәм Миңнеханов. – Бу чыннан да бик мөһим. Һәр процент ставкасы ул – акча, ул – маржа (товарның үзкыйммәте һәм сатыла торган бәя арасындагы аерма). Сезнең аерма Үзәк банк ставкасына карап үзгәрә бит. Ә кайвакыт, сатуны арттыру өчен, бәяләрне күтәрергә туры килә.

Сүз уңаеннан, очрашу тәмамланган сәгатьләрдә Үзәк банкның төп ставканы 14 проценттан 11 процентка калдыруы билгеле булды.

Татарстанның бизнес-омбудсмены Фәрит Габделганиев, Президентның эшмәкәрләр белән очрашуына нәтиҗә ясап, күтәрелгән сораулар бизнесның вазгыятькә тиз яраклашуын, бүгенге икътисади шартларда үсәр өчен яңа мөмкинлекләр эзләвен күрсәтә дип билгеләде.

– Сорауларның шактые социаль эшмәкәрлекне үстерүгә кагылышлы булуы кешеләрнең һәм җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итеп, керем кертү мөмкинлегеннә яңа төр бизнеска ихтыяҗ барлыгы турында сөйли, – диде Фәрит Габделганиев.

Зөһрә САДЫЙКОВА

САК КАРАШ КИРӘК

Республикада җылылык һәм су белән тәэмин итү тармагында инвестиция программасы булдырылачак. Министрлар Кабинетында җылылык бирү сезонына әзерлеккә багышланган утырышта бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әйтте. Аның фикеренчә, әлеге программа җылылык һәм су белән тәэмин итү челтәрләрендәге авария мәсьәләләрен хәл итәр өчен кирәк.

«Инвестицияләрсез булдыра алмыйбыз. Шуңа күрә бу юнәлешне алып барыр өчен, безгә кайбер программаларны киметеп яки туктатып торырга туры киләчәк», – ди Рөстәм Миңнеханов.

Проблемалар юк түгел. Татарстанның төзелеш, архитектура, торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин әйтүенчә, республикада җылыту чорында 261 көндә 2741 авария булган.

– Һава шартлары аварияләр санына йогынты ясый торган факторларның берсе булып тора. Шулай ук аварияләр челтәрләр тузу аркасында да килеп чыга. Су белән тәэмин итү һәм юынтык су чыгару өчен кулланыла торган корылмаларның – 33, җылылык белән тәэмин итү челтәрләренең 37 проценты тузган. Аларны алыштырырга кирәк. Әлмәт һәм Бөгелмә районнары, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә аварияләр саны буенча Казаннан гына калышып, беренче өчлеккә керде, – диде министр.

Торак-коммуналь хезмәтләр өчен халыкның 8,8 млрд сум бурычы бар. Республикада берничә ел дәвамында халыктан түләүләр җыю буенча уртача еллык күрсәткеч 98 процент тәшкил итә. Торак-коммуналь хуҗалык оешмаларының энергия ресурслары өчен – 360 миллион, газ өчен 296 миллион сум әҗәте бар.

Утырышны уздырган Татарстанның Премьер-министры Алексей Песошин сүзләренчә, районнар һәм торак-коммуналь хуҗалык оешмаларының килешеп эшләве узган сезонга әзерлекне билгеләнгән вакытка башкарып чыгарга мөмкинлек биргән. 45 районның 40ы әзерлек паспортларын вакытында алган. Арча, Мөслим, Питрәч, Сарман районнары һәм Казан шәһәре әзерлек паспортларын ала алмаган. Республикада 3146 котельный, 17476 күпфатирлы йорт, 3333 мәгариф, 2013 сәламәтлек саклау, 1962 мәдәният, 311 спорт һәм яшьләр, 175 социаль яклау объектлары әзерләнгән.

– Челтәр компанияләреннән чираттагы җылылык бирү чорына әзерлек вакытында ремонт эшләренең сыйфатын контрольдә тотуны катгыйландыруны сорыйм. Киләчәктә, быелгы сезондагы кебек, Чаллы, Әлмәт, Бөгелмә шәһәрләрендә булган җитди аварияләрне булдырмас өчен, җылылык һәм су белән тәэмин итү челтәрләренең тузуын вакытында ачыкларга һәм алыштырырга кирәк, – диде Алексей Песошин.

Экология, технология һәм атом-төш күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе башлыгы Азат Мөбарәкшин әйтүенчә, республиканың 850 котельныенда 3300 кимчелек табылган. Челтәрләрдәге төп проблема – әлеге дә баягы аларның тузуы. Кайбер оешмаларда махсус укытылган кешеләр юк икән. Татарстан Президенты, электр, җылылык оешмаларында эшенә салкын караган җитәкче эшләргә тиеш түгел, дигән фикердә.

– Андыйларны эштән алырга кирәк. Ничек инде ул үз оешмандагы торбалар, чыбыкларның торышын белмичә эшлисең? Без төзибез, ә кайбер җитәкчеләр булганны сакламыйча, төзекләндерү сорый. Һәр җитәкче подвалында нәрсә бар, җылылык, электр челтәрләре нинди кыяфәттә, спорт объектлары, боз, йөзү сарайлары, мәктәп, хастаханәләр ни хәлдә – барысын да белеп торырга тиеш, – диде Президент, катгый итеп. – Һәр объектның хуҗасы булырга тиеш. Ремонтка акча сорау җиңел ул. Үзең хуҗа булган җирне вакытында карап торсаң, күңелсезлекләр килеп чыкмас иде. Кышка кергәнче, барлык объектларда, мәктәп, спорт залларында тәртип булсын!

Утырышта кышка әзерлек хакында тәсфилләп сөйләнде. Нинди хаталар җибәрмәскә, ничек эшләргә кирәклеген сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов, кышкы сезонны яхшы чыксак та, үзен аварияләр саны борчуын әйтте. «Республикада авария очрагы өчен техник запас сакларга кирәк. Ул ел саен 80,4 миллион сумга тулылана. Әгәр кирәк икән, аны индексацияләргә дә мөмкин», – диде ул.

Белсеннәр, алсыннар, эшләсеннәр

Шәхси хуҗалыкларга ярдәм итү һәм авылда эшмәкәрлекне үстерү мәсьәләләренә багышланган зона киңәшмәләренең дүртенчесе Чирмешәндә узды. Биредә Кама аръягы зонасына керүче 10 район вәкилләре җыелды.

tatarstan.ru

Моңа кадәр шундый өч чара Буа, Кукмара һәм Мөслим районнарында үткәрелгән иде. Семинар-киңәшмәләрнең йомгаклары буенча беркетмә төзелеп, анда фермерлар күтәргән барлык мәсьәләләр чагылыш табачак. Аларны дәүләт ярдәме программалары аша этаплап хәл итү өчен кирәк бу. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин искәрткәнчә, узган семинарлар йомгаклары буенча беркетмәдә күрсәтелгән барлык бурычлар тулаем үтәлгән.

Парламент башлыгы әйтүенчә, республикада авыл җирлегендә кече хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирелә. Һәр ел саен республика бюджетыннан әлеге максатка грантлар һәм субсидияләр рәвешендә 2 миллиард сумнан артыграк акча тотыла. 2016 елдан шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәме турында республика законы гамәлдә. Парламент башлыгы билгеләп үткәнчә, быел да ярдәм чаралары сакланып калган. Шул ук вакытта федераль бюджеттан финанслау элеккеге күләмдә калса, республика бюджетыннан 8 процентка артачак.

«Республикада авыл җирлегендә үз бизнесын үстерергә, үз эшен башлап җибәрергә яки фермер хуҗалыкларын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны ныгытырга теләүчеләргә зур финанс ярдәме күрсәтелә. Район хакимиятләре авыл җирлекләре башлыкларының бурычы – мондый актив кешеләрне табып, аларга авылны үстерү буенча дәүләт программалары турында сөйләү, документлар рәсмиләштерүдә, проектларны яклауда ярдәм итү. Мөмкинлекләр гаять зур, алардан тулысынча файдаланырга гына кирәк. Субсидияләр һәм грантлар иң отышлы шартларда бирелә, боларның барысы да авылда яшәүчеләр хакына эшләнелә», – дип йомгак ясады Фәрит Мөхәммәтшин.

КОТЛАУЛАР ӨЧЕН РӘХМӘТ

Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИН 75 яшьлеге уңаеннан котлаулар өчен газетабыз аша рәхмәтен белдерде.

«Юбилеем уңаеннан килгән котлаулар өчен сезнең басма аша ихлас рәхмәтемне белдерәсем килә. Ихтирамыгыз һәм Татарстан Республикасы халкы хакына эшчәнлегемне күрүегез минем өчен бик кыйммәт. Үз чиратымда, барлык татарстанлыларга сәламәтлек, иминлек, тынычлык һәм бәхет телим!» – дигән республика парламенты спикеры.

Айдар ШӘЙХИН

МЕНТАЛЬ ХОКУК БОЗУЛАР

Бу урында озак шәрехлисе дә килми. Менталь (акыл, баш мие эшчәнлеге белән бәйле) хокук бозулар 2022 елда бер дәүләтнең дә хокук системасында теркәлмәгән, бәлки, киләчәктә, андый төр канунсызлыклар да пәйда булыр. Ә әлегә авторның кулланырга теләгән, әмма ни өчендер буталып киткән, ә аннары баш мөхәррир дә искә төшермәгән сүзе – *менталь тайпылыш* (ментальные нарушения).

ЯСАРГА ЭШЛӘРГӘ

Газетабызның бер укучысы *«салат эшлибез»* гыйбарәсен ишетеп мөрәҗәгать итте. Әйе, бу – хаталы җөмлә. Әгәр дә интернет чыганакларга күз салсак, «салат эшләү» кебек тезмәләрнең башлыча башкорт телендәге ресурсларда кулланылуын күрербез.

Татар телендә *ясау* (ясарга) дигән фигыль дә, исем дә бар. Исем буларак ул яхшы, сыйфатлы, пакь дигәнне аңлата. Ә фигыль буларак исә төп мәгънәсе белән әйбер җитештерү; оештыру, үткәрү дигәннәрне аңлата (монда һәм алга таба билгеләмәләр Татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән алынды).

Эшләү исә беренче чиратта нинди дә булса эш башкару, эш белән шөгыльләнү, эшчәнлек күрсәтүне аңлата. Әйе, *эшләү* сүзе белән дә нәрсәне дә булса җитештерүне аңлатырга була. Ләкин бу аның төп мәгънәсе түгел.

Кыскасы, салат эшләмәгез, салат ясагыз. Ашларыгыз тәмле булсын!

ШОУ ШАУ ТАМАША

Газета укучылары хәбәр итүенчә, кайвакытта рус теленнән кергән инглиз сүзе *шоу*ны урынсыз рәвештә *шау* дип язалар икән. Аның татарча язылышының кагыйдәсе рус теленә бәйле: безгә русчадан кергәч, без аны рус телендәгечә язабыз. Рус теленнән алынган сүзләрне татар орфоэпиясе һәм орфографиясе кагыйдәләренә яраклаштыру-яраклаштырмау безнең сәхифә кысасында карала торган сорау түгел, шуңа күрә кагыйдәгә катгый рәвештә буйсынабыз һәм *шоу* дип язабыз. Инглизчәләтеп, show сүзенә якынайтып әйтергә теләгән кешеләр дә *шау* дип язып шаулаша алмый: show дип, якынча әйткәндә, [шәу] дип әйтелә.

Шоу сүзен татарчалатып бетереп, *тамаша* дип кенә язарга тәкъдим итүчеләр дә бар. Әйе, кайвакыт бик тә урынлы була, чөнки шоу – тамашаның бер төре. Әмма сүзлек шоуны «телевидение, эстрада, цирк һ.б.ш.да төрле күңелле, кызык чараларга бай булган зур тамаша» дип тә бирә әле. Шуңа күрә үзенчәлекләрен ассызыкларга кирәк булганда яки шоу-бизнес сүзендәге кебек мәгънә төрлеген күрсәтергә кирәк булган очракта, һичшиксез, һич курыкмыйча *шоу* сүзен кулланырга кирәк. Өстәвенә тамаша сүзе дә – гарәп теленнән кергән алынма сүз.

Игътибарыбызны таләп итә торган үзенчәлекне дә онытмыйк. *Шоу* сүзе татар теленең табигый кагыйдәләренә буйсынмый, шуңарга ахырдагы у хәрефе кушымча ялгаганда үзгәреш кичерми: *шоуы, шоуына, шоуыбыз.* Ә инде шовы, шовына, шовыбыз дип язу дөрес түгел.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Алла ризалыгы өчен

Кызганыч, әмма бу язмамның герое, олы яшьтәге бер апа турында тәгаен генә берни дә яза алмыйм. Аның кайсы районда, кайсы авылда яшәгәнен дә әйтмим һәм моның сәбәбе бар.

Чираттагы сәфәремнең берсендә фәлән районның фәлән авылындагы мәчетне күреп сокланган идем. «Кем салдырды моны?» – дип сорадым. Исемен әйттеләр, фәлән апа, диделәр. Мәчет каршында гына үзенең йорты да бар икән, бик матур, зәвыклы итеп салынган иде ул. Тик хуҗабикә өйдә юк булып чыкты. Казанда яши, авылга кайтып кына йөри, диделәр. Монда чагын туры китереп очрашасы, ачылып китеп рәхәтләнеп сөйләшеп утырасы килә иде бу изге җанлы апа белән.

Берәр атна вакыт узгач, авыл җирлеге башлыгына шалтыраттым, кем икәнлегемне әйттем дә теге апаның авылдамы-юкмы икәнен сорадым. Ышанасызмы-юкмы, җирлек башлыгы: «Риман абый, зинһар, кайта күрмәгез! Ул сезнең белән барыбер сөйләшмәячәк», – диде.

– Ничек инде сөйләшмәячәк?

– Менә шулай. Үзен мактаганны бер дә яратмый. Узган ел авыл җыенында аның изге гамәлләрен санап, халык исеменнән рәхмәтләр укыган идек. Ул бит әле елар буе җыеп килгән хәләл акчасына мәчет салдыру өстенә авыл эчендә юлларны да рәтләтте. Җыенда катнашмаган иде, үзен телгә алганны ишеттергәннәр дә, минем өйгә килде бу. «Сеңлем, бүтән алай итмә, үзеңә гөнаһ алма, мин бөтенесен дә Алла ризалыгы өчен эшләдем һәм эшлим», – диде. Менә шул, Риман абый, язсаң да, минем исемне кыстырма, мин әйтте дип әйтмә. Ул апа – бик авырлыкта үскән, хет туйганчы ашап булмасмы, дип эш эзләп авылдан чыгып киткән, тамак хакына төрле эшләрдә эшләгән, аннан соң үз тырышлыгы, акылы белән югары дәрәҗәләргә ирешкән кеше...

Җирлек башлыгы, артыгын сөйләп ташладым, ахрысы, дип уйлапмы, туктап калды. Мин һаман төпченәм: «Шундый-шундый кеше шалтыратты, бик күрәсе килә, дип әйтеп карамыйсыңмы соң?» – дидем.

– Юк, Риман абый, әйтмим дә, үпкәләмә дә, яме!

Нигә үпкәлим ди инде, сеңлем җаным. Син миңа утырып уйлар өчен азык бирдең. Габдулла Шамуковның «Сәрби әби тавыгы» дигән мәсәле искә төште әле. Хәтерләсәгез, чикләвек хәтле күкәй салып, бөтен кетәклекне аякка бастырган тавык турында ул. Сәрби әби тавыгына охшаган бәндәләр арабызда очраштыргалый әле. Берәр кирәкле гамәл кылынса, «Аны мин эшләдем, минем өлешем күбрәк керде...» кебек сүзләр әйтеп талашып бетүчеләр дә бар. Берәүнең: «Мәчеткә кереп, мең тәңкә сәдака бирдем бит әле, брат», – дип адым саен сөйләп йөргәнен дә хәтерлим.

Халыкның: «Яхшылык эшлә дә суга сал – халык белмәсә, балык белер», – дигән бик мәгънәле сүзләре бар. Дөрес, без хәләл акчасына изге гамәлләр кылучылар турында сөйләргә, язарга тиеш, әмма анысы да гыйбрәт өчен, шул кешедән үрнәк алып, башкалар да эшкә тотынсын өчен.

Ә кылган игелекләрнең әҗере кешегә барыбер кире әйләнеп кайтачак ул.

Бу язманы укыгач, шат: «Нинди апа икән ул, кайсы якныкы икән?» – дип кызыксынучылар булыр. Сорамагыз да, әйтмим дә, гөнаһына керәсем килми. Ә язганнарым уйдырма түгел, булган хәл.

ХӘЛӘЛ – АЛГАРЫШ БИЛГЕСЕ

Быел «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» очрашуы үзенчәлекле шартларда үтте. Бердән, Татарстан туфрагында ислам дине кабул ителүнең олы юбилее. Тарихи бу факт төньяк киңлекләрдә яшәүче халыкларның тормышында хәлиткеч роль уйнаган. Татарлар гасырлар буена ислам динен һәм гыйлемен таратучы пассионар халык буларак үзләрен танытып килделәр һәм эстафета бүген дә дәвам иттерелә. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең зур датасы тиктомалдан гына Россия күләмендә билгеләп үтелми. Бу бер яктан вакыйганың тарихи әһәмиятен расласа, икенче яктан Татарстанның һәм татарларның бүгенге Россия тормышында хәлиткеч әһәмияткә ия төбәк һәм халык булуын дәлилли. Казан халыкара масштабта эш йөртерлек потенциалы барлыгын күрсәтә, чөнки алтмышка якын илдән зур сәясәтчеләр, лидерлар, дипломатлар һәм җәмәгать эшлеклеләре «KazanSummit» түбәсе астында бергә җыелганнар һәм мөһим проблемаларны уртага салып хәл итәләр икән, бу – үзе үк зур күрсәткеч. Киләчәктә башкаланың ислам финанслары һәм ислам бизнесы үзәгенә әверелү ихтималлыгының зур булуына ишарә итә.

kazansummit.ru

Икенчедән, дөнья масштабында ислам яңарышы бара. Моннан йөз ел элек хәлсезләнгән һәм дөньядагы үзенең лидерлык ролен югалта башлаган мөселманнар яңадан дөнья сәясәте һәм икътисады аренасына глобаль көч буларак чыгарга җыеналар. Дистәләгән агымга бүленгән һәм таркау хәлгә килгән өммәт уртак максатлар тирәсендә берләшү нокталарын эзли. «KazanSummit» шул нокталарның берсенә әверелү мөмкинлеге белән дә зур әһәмияткә ия.

Өченчедән, глобаль икътисад бүген зур тетрәнүләр кичерә: сәүдә элемтәләре өзелә, мәйданга финанс түнтәрелешләре чыга, державалар бер-берсен санкцияләр кертеп тешлиләр, үзәктән качучы көчләр активлаша. Боларның барысының да нигезендә процент капиталы ята. Мәгълүмдер ки, ислам процент капиталын (рибаны) катгый тыя, аны һәлакәткә илтүче зур җиде гөнаһның берсе буларак карый. Әмма тәүхидкә (бер Аллаһка гыйбадәткә) корылган дин тыеп кына калмый, альтернатива да тәкъдим итә. Сәүдәне һәм җитештерүне финанслауның шәригатькә туры килгән ысулларының тулы бер комплексы бар һәм шунысы кызык: алар хакында хәзер мөселман булмаган финансчылар да яхшы белә һәм күп вакыт аларны югары бәяли. Казан очрашуы кысасында Саклык банкы өлкән вице-президенты Олег Ганеев чыгышы – шуның ачык мисалы. Вакытында Россиянең элекке хезмәт һәм социаль үсеш министры Александр Починок ислам салым системасы һәм аның өстенлекләре турында бик тәфсилле чыгыш ясаган һәм аның ул чыгышы халыкара күләмдә зур яңгыраш тапкан иде. Күрәбез, ислам финанслары бүген мөселман булмаган сәясәтчеләрнең дә игътибар үзәгендә. Ул игътибарны 2008–2010 еллардагы бөтендөнья финанс кризисы да көчәйтте, чөнки процент капиталына корылган Көнбатыш банклары җимерелгән һәм үзәк банкларның ярдәменә мохтаҗ булган ул елларда ислам банкингы үзенең тотрыклылыгы һәм ышанычлылыгы белән гомум игътибарны җәлеп итте.

Менә болар барысы да «KazanSummit»ның әһәмиятен арттыра. Мондый берләшү һәм уртак үсеш юлларын эзләү мөселманнар яшәгән илләр өчен мөһим, ярым изоляция кысасында калган Россия өчен икеләтә әһәмиятле. Әйе, әйе, Көнбатышның көчле басымы астында мөселманнар да, хәтта гарәп илләре дә ислам икътисадыннан ераклашканнар, глобаль капитализм кочагына ауганнар иде. Үткән гасырның икенче яртысында ислам яңарышы дулкынында беренче ислам банклары бик авырлык, аерым энтузиастларның тырышлыгы һәм аяусыз көрәше белән генә яңадан мәйданга чыкты һәм Көнчыгышта да, Көнбатышта да шәригатьчә финанслау җәелә башлады, Россиядә дә, ниһаять, аның беренче карлыгачлары күренә.

Хәләл индустриягә һәм хәләл финанслауга хәзер дөньяда ихтыяҗ бик зур. Монда бабалары мөселман булган халыкларның яңадан күпләп исламга кайтуы да роль уйный, мөселман булмаганнарның да хәләлгә ышанычы товар дип караулары да сорауны көчәйтә. Мәскәүдәге танылган рус журналисты, мөселманнарга алай бик мөкиббән үк китмәгән рус патриоты бервакыт социаль челтәрләрдә итне бары тик Мәскәүдәге хәләл кибетләрдән генә алуын, чөнки аларныкы тәмле, чиста һәм ышанычлы булуы турында пост биргән иде. Танылган рус дизайнеры, кием-салым модасы тарихы белгече Александр Васильев моннан алты ел элек үк ислам мәдәниятенең киләчәктә кием-салымга төп ихтыяҗны билгеләячәген ассызыклап: «Никакого другого будущего у моды вообще нет – мода разделась окончательно. И, безусловно, мусульмане завоевывают все больше и больше интереса. Это значит, что эта тенденция стала очень глобальной», – дигән иде. Аны кайбер башка рус дизайнерлары да куәтләде. Менә шуннан әйтеп карагыз: хәләл ризык, хәләл кием, хәләл дарулар, хәләл товарлар индустриясенең киләчәге зурмы, кечкенәме?

Дөньякүләм бара торган бу процессның үзәгендә Татарстан торуы һәм шуңа омтылуы безне сөендерә, билгеле. Бу инде гадәти омтылыш кына түгел, ә халыкара масштабта танылу алу, ышаныч яулау. Бөтендөнья хәләл көнә рәисе Мөхәммәд Җиннә: «Татарстан мөселман һәм мөселман булмаган илләрне хәләл продукция өчен берләштерүче мөһим уенчы булып тора», – дип билдергән икән, бу – зур танылу билгесе. Аның безнең республиканы киләчәктә хәләл хабка әйләндерү идеясе зур мөмкинлекләр вәгъдә итә. Хабның мәгънәсе үзәк, туплану урыны икәнен искә төшерсәк һәм спикерның хәләл индустрия мөселман булмаган базарларга да чыккан очракта товар әйләнеше 3 триллион доллардан 10 триллион долларга кадәр үсәчәге турындагы фаразы Татарстан алдында торган перспективаның зурлыгын дәлилләмимени?

Татарстан җитәкчелеге мөселман илләре белән һәрвакыт тыгыз элемтәләрне үстерде һәм «KazanSummit»ның уникенче тапкыр уздырылуы һәм торган саен масштаблырак була баруы – шул эшчәнлекнең югары орбитага чыгуы ул. Әлегә проблемалар күп, әлбәттә. Россиядә мөстәкыйль ислам банкы булдыру яисә халыкара бер ислам банкының бүлекчәсен булдыру кирәк, әмма Россия законнары моңа юл куеп ук бетерми. Дипломатик рәвештә бу юнәлештә эш алып барыла, билгеле. Әлегә Саклык банкы кысасында гына чикләнгән эш алып барырга туры килә. Монысы да казаныш инде аның. Вәләкин бары мөселман финансчы белгечләрен генә туплаган ышанычлы банк булдыру көн тәртибендә төп бурычларның берсе буларак кала бирә. «Хаб» идеясен шуннан башка тормышка ашырып булмый да торгандыр, мөгаен. Әгәр тормышка ашырыла калса, йөз миллиардлаган, хәтта триллионлаган долларлык финанс агымнары безнең аша үтәчәк дигән сүз. Бу Россия масштабындагы гигант инвестицияләрне, яңа технологик чишелешләрне аңлата. Беренче карашка бу фантастика булып тоела, әмма кайчандыр хәләл үзе дә безгә төш шикелле генә тоела иде, хәзер базарларны яулый. Мәскәүдә бу юнәлешнең әһәмиятен аңлыйлар, Татарстанга ышаныч белдерәләр, шулай булгач, «юлны баручы яулый».

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ҺӘР ПОЧМАГЫ КАДЕРЛЕ

Алыргамы, сабыр итәргәме? Үз куышын булдырырга хыялланган күпләр бүген шулай дип баш вата. Ник дигәндә, май башыннан Россиядә ташламалы ипотеканың процент ставкасы төште. Икенчел базардагы фатирлар да арзаная башлады. Өстәвенә кичә Үзәк банк чираттан тыш утырышта төп ставканы 11 процентка калдырды. Ипотека процентлары тагын да төшәр дип өметләнергә кирәкме? Бүген фатир алу өчен кулай вакытмы? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

Айлык түләве куркыта

Моннан ике ай элек белгечләр тарафыннан янгыраган фаразлар акрынлап чынга аша башлады. Хәтерләсәгез, 1 мартта Россия Үзәк банкы төп ставканы 20 процентка кадәр арттырып куйды. Бу соңгы еллардагы рекордлы күрсәткеч дип бәяләнде. Аңа кадәр төп ставка 9,5 процент тәшкил итә иде. Үзәк банк мондый адым икътисади чикләүләр аркасында бәяләрнең тотрыклылыгын тәэмин итү, халыкта булган акчаның кыйммәтен саклау өчен кирәк дип аңлатты. Үзәк банкның көтелмәгән хәбәреннән соң банклар барлык төр кредит һәм кертемнәргә ставканы арттырды. Күпләрнең төп ярдәмчесенә әверелеп барган ипотека ставкалары 15–20 процентка ук җитте.

Шок хәлендә калдырган ул көннәрдә белгечләр, бу – вакытлы күренеш, бик тиздән ставкалар төшәчәк әле, дип тынычландырды. Шулай булды да. 10 апрель көнне Үзәк банк төп ставканы – 17 процентка, 29 апрельдә 14 процентка кадәр төшерде. 10 июнь көнне бу мәсьәлә кабат каралырга тиеш иде. Әмма белгечләр бу көнне көтеп тормады. Кичә Үзәк банкның чираттагы утырышы барышында төп ставка 11 процентка калдырылды.

Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов ел азагына кадәр төп ставка 10 процентка калыр дип фаразлый. «Төп ставка ул – еллык процент. Илдәге теләсә кайсы банк Үзәк банктан шул процент белән кредит ала ала. Төп ставка түбәнрәк булган саен, без – физик затлар алган кредит ставкалары да кечерәк була. Төп ставканың түбән булуы юридик затлар өчен аеруча мөһим. Ник дигәндә, безнең икътисад, нигездә, кредит акчасына яши. Товар җитештерүче оешмалар өчен кредит ставкалары түбән булган саен, кибеттәге азык-төлек бәяләре дә арзанрак булачак», – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Фәнис Хөсәенов фикеренчә, төп ставкага бәйле рәвештә алга таба процент ставкалары да төшәчәк. Әмма бу базарны әллә ни җанландырмаячак, дип саный ул. Ник дигәндә, соңгы арада халыкның керемнәре шактый кимеде. «Хәтта төзүчеләр тарафыннан ясалган ташламалар да сатылган фатирлар санын арттырырга ярдәм итә алмый. Бүген фатир алучылар аның бәясеннән бигрәк, айлык түләүнең күпме булачагына игътибар итә. Хәзерге процент ставкалары белән бик зур сумма килеп чыга бит. Андый айлык түләүне каплап бару күп кенә гаиләләрнең көченнән килми. Кулында торак алырлык акчасы булган кеше дә фатир алырга ашыкмый. Ник дигәндә, фатир бәяләре төшә башлады. Әлегә икенчел торак базарындагы фатирлар гына очсызлана. Якын киләчәктә, беренчел торак базарында да бәяләр төшәр дип көтәбез», – ди белгеч.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Балкон – бүләккә

Татарстанның риелторлар гильдиясе вице-президенты Андрей Савельев, торак базары ипотека ставкалары элеккеге кебек үк 7–9 процентка кадәр төшкән очракта гына җанланачак, дигән фикердә.

– Яңа төзелгән йортлардагы фатир бәяләре үзгәрешсез калды. Соңгы арада күп кенә төзүчеләр «һәр 20 нче метр – бүләккә», «балкон – бүләккә» ише акцияләр дә игълан итә башлады. Мисал өчен, 2 метрлы балконлы 50 квадрат метрлы фатир алсагыз, сез шуның 48 квадрат метры өчен генә түлисез булып чыга.

Татарстанда төзелгән өлешләп түләү килешүләре

	2021	2022
Март	1316	2936
Апрель	1932	2521

Сорау кимегәндә, халыкны шул рәвешле җәлеп итәргә тырышулар – гадәти хәл, – ди ул.

Росреестр идарәсе мәгълүматларына караганда, апрель аенда Татарстанда яңа төзелгән йортлардагы фатирларга сорау 30 процентка арткан. Әмма белгечләр бу саннарга сөенергә иртәрәк, дип саный. Ник дигәндә, бу күрсәткеч ташламалы ипотеканы түбән процентлы чагында эләктереп калырга өлгерүчеләр хисабына арткан. Әле март аенда гына 7 процент тәшкил иткән ташламалы ипотека апрель аенда инде 12 процентка җитте.

Бу, үз чиратында, фатирларга булган сорауны да киметте. Саннар теленә күчсәк, апрель аенда Татарстанда 3,4 миллиард сумлык фатир сатылган. Бу, март ае белән чагыштырганда, 2,4 тапкыр күбрәк. Мартта республикада фатирлар 8,2 миллиард сумлык сатылган булган. Апрель аенда Татарстанда ипотека алучылар саны да, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 70 процентка кимрәк булган. Ил күләмендә дә саннар шул чама. Шушы вазгыятькә бәйле рәвештә Россия Хөкүмәте ташламалы ипотека ставкасын 12 проценттан 9 процентка кадәр төшерү турында карар кабул итте.

Иң кулай чак

Тәҗрибәле риелтор Эльвира Рәхимуллина сүзләренә караганда, бу яңалык, бер яктан, халыкның мондый кредитка дәгъва итә алу ихтималын арттырган. «Шул ук вакытта ташламалы ипотека ставкасы төшү аркасында күпләр көтү режимына күчте. Якын арада аның проценты тагын да төшмәсме дип сабыр итә алар. Бу исә, үз чиратында, торак базарында сорауның кимүенә китерде», – ди белгеч.

Соңгы арада икенчел базардагы торак бәяләренең төшүен дә аларга булган сорауның кимүе белән аңлата ул. «Халыкның матди хәле дә авырайды. Бүген икенчел базарда кредит ставкалары бик югары. Иң түбән дигәне дә 13,9 процент тәшкил итә. Шуңа күрә милекчеләргә, фатир сатканда, бәяләрне шактый төшерергә туры килә. Юкса фатир бик озак сатылачак. Әмма аларның барысы да фатир бәясен төшерергә әзер түгел. Тагын бер айдан фатирының тагын да арзанаячагын аңлаган кеше, ничарадан бичара, моны эшләде инде. Кемдер сатуга куйган фатирының бәясен – 5 процентка, кемдер 10 процентка төшерде», – ди Эльвира Рәхимуллина.

Яңа фатирлар базарындагы вазгыять исә башкачарак. Бирегә торак бәяләре үзгәрешсез калган. Белгеч моның берничә сәбәбен атый. Беренчедән, яңа төзелгән йорттан фатир алучыларга дәүләт тарафыннан субсидияләнгән кредитлар бирелә. Өстәвенә аларга еш кына төзүчеләр үзләре дә ташлама ясый. Аның күләме бөтен түләү чорына 0,1 проценттан башлана. Соңгы арада төзелеш материаллары да бик нык кыйммәтләнде. Бу шулай ук яңа йорттагы фатирларга арзанаерга ирек бирми.

«Шулай да бүген яңа төзелгән йортлардагы фатирларга сорау зуррак. Монда һаман да шул дәүләт тарафыннан субсидияләнгән кредит алу мөмкинлеге, төзүчеләрнең дә ташлама ясавы зур йогынты ясый. Икенчел базардагы фатирларга сорау исә якынча 80 процентка кимеде. Ник дигәндә, тотылган фатир алучыларның нәкъ менә шулкадәр өлеше үз куышын ипотека хисабына булдыра иде», – ди Эльвира Рәхимуллина.

Риелтор сүзләренә караганда, бүген үз куышын булдырырга җыенган кешеләр күбрәк бер бүлмәле фатирга өстенлек бирә. Соңгы арада шәһәр читендә йорт алырга теләүчеләр саны да арта башлаган. Бердән, йорт фатирга караганда арзангарак төшә. Өстәвенә йорт алган кеше дә ташламалы ипотека кредитларыннан файдалана ала. Аерым алганда, йорт сатып алучы «Гаилә ипотекасы» программасы нигезендә – ким дигәндә 5,9 процент ставка, дәүләт субсидияләве нигезендә 8,7 процент белән кредит рәсмиләштерә ала.

– Фатирның квадрат метр бәясе аңа сорауның ни дәрәҗәдә зур булуына, кайда урнашуына, йортның кайчан төзелгәнлегенә, аның нинди классны булуына да бәйле. Шәһәр янындагы берничә ел элек төзелгән йортларда, әйтик, фатирларның бер квадрат метр бәясе 80–90 мең сум тирәсендә тирбәлә. Казан эчендә урнашкан фатирларның бер квадрат метры бүген 160 мең – 200 мең сум тора. Башкаладагы иң кыйммәтле фатирлар Вахитов һәм Яңа Савин районнарында урнашкан. Иң арзаннары – «Осиново», "Радужный" торак комплексларында, – ди белгеч. Шул рәвешле бүген Казан читендәге 50 квадрат метрлы бер бүлмәле фатир алыйм дисәң дә, кесәңдә ким дигәндә 4 миллион сум (!) акчаң булырга тиеш дигән сүз бу. Шәһәр эчендә шундый ук фатир 8 миллион сумга төшәчәк.

– Торак базарындагы бүгенге вазгыятьнең кайчанга кадәр дәвам итәчәген беркем дә төгәл әйтә алмый. Әмма шунысы хак: Казан – инвестицияләр ягыннан алдынгы шәһәр. Шуңа күрә биредә торак бәяләре һәрчак югары булачак, – дип саный Эльвира Рәхимуллина.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ФАТИР САТЫП АЛЫРГА ҖЫЕНУЧЫЛАРГА БЕРНИЧӘ КИҢӘШ

1 Фатир сатып алганда бу юнәлештә эшләгән белгечкә мөрәҗәгать итү хәерле. Риелтор сезгә беренчел базардан яхшы процент ставкалы кредит рәсмиләштерергә, икенчел базардан фатирны зур ташлама белән сатып алырга ярдәм итә алачак.

2 Бүген икенчел базардан торак сатып алганда алдану куркынычы да артты. Ник дигәндә, милекче банкротлыкка чыккан яки банкрот хәлендә булырга мөмкин. Шуңа күрә фатир сатып алганда документларны юридик яктан яхшылап тикшерергә, килешүне дөрес итеп тутырырга кирәк. Шуңа күрә монда белгечтән башка булмый.

3 Хәзер фатир алып калу өчен кулай вакыт. Кулыгызда «тере» акча булса, икенчел базардагы торакны карарга киңәш итәр идем. Фатир хакының бик аз өлешенә генә кредит алган очракта да шушы төркемгә кергән фатирларга өстенлек бирү хәерлерәк. Ник дигәндә, бүген икенчел торак базарында бәяләр түбән тәгәргәндә бик отышлы бәядән фатир алып калырга була. Кулдан фатир алганда бәяне тагын бераз төшертеп тә була. Яңа төзелгән йортлардагы фатирларны да бик отышлы процент ставкалы кредит нигезендә алырга була. Әйтик, бүген хәтта өч бүлмәле фатирны да айлык түләве 16900 сумнан да артмаслык кредит шартларында эләктереп калырга мөмкин.

vk.com

КЫЙБЛАҢ БАРМЫ?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Бүгенге буын белән нишләргә? Бер калыпка салып тәрбияләү отышлымы һәм, иң мөһиме, бу мөмкинме? Аларга идеология дигән рухи азык кирәкме? «ВТ» яңа буынның нинди булуын һәм аларның кызыксынуларын белеште.

«Алтын урталык» эзләгәндә

Яшьләрне тәрбияләү дигәндә, элек уңышлы эшләп килгән пионерия оешмаларын еш телгә алалар. Шуңа хәзер аны торгызу, торгызып булмаса, аңа охшаш берәр оешма булдыру турында сөйләшә башладылар. Башларында җил уйнаган яшьләрнең аңына идеология кирәк дип борчылудан инде. Ансыз дөнья кая барып җитәр бит, билгесез. Үсеп килүче буынны алдан ук тормышка әзерләргә, тәрбияләргә кирәк. Мәктәп һәм гаиләдәгесе генә җитми.

Оешма булдырырга теләүләре әйбәт анысы. Иш янына куш булыр иде ул. Әмма аның хәзерге балаларга якын булуы мөһимрәктер әле. Моны хәтта ил башлыгы Владимир Путин да берничә тапкыр әйткәне булды. «Өстән кушканга» түгел, бшта балалардан сорыйсы. «Һәрвакыт әзер!» ише шигарьләр, кызыл галстук, тарихи шәхесләрнең батырлыгы белән генә кызыктырып булмаячагы көн кебек ачык. Яңа оешма андый булмас, диләр.

– Оешма вакыт чынбарлыгына һәм, гомумән, цифрлы икътисад, мәгълүмати технологияләр өлкәсе үсешенә туры килергә, шулай ук яшьләрнең кәефен исәпкә алырга тиеш, – дип фикере белән уртаклашты Дәүләт Думасы каршындагы Яшьләр парламенты рәисе Дмитрий Шатунов. – Пионерия бит ул Советлар Союзы чоры өчен актуаль, үз вакыты өчен кирәкле иде. Хәзер инде безнең илдә бөтенләй башка тарихи чор. Пионериянең 100 процент күчермәсен бүген кабатлау нәтиҗәсез булачак, ул актуаль түгел.

Элегрәк Татарстанның яшьләр эшләре министры булган, хәзер Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе урынбасары Дамир Фәттахов әйтүенчә, балалар оешмасына яшь буынның иң актив вәкилләре җәлеп ителә. Шул ягы да бар: күп кенә иҗтимагый хәрәкәтләр еш кына бер үк балалар белән эшли. Ә хәзерге вазгыятьтә кеше берничә төрле оешманың әгъзасы булса да начар түгел. «Безгә балалар оешмалары массакүләм, кызыклы, аларга ихтыяҗ булсын өчен күп эшлисе бар. Хәзер андый оешмаларны берләштерү (консолидация), яңа бурычларга игътибарын юнәлтү соравы килеп баса», – дигән фикердә экс-министр. Дамир Фәттахов искәртүенчә, балалар-яшүсмерләрдән элемтә алгач кына, нинди оешма һәм аның бурыч-максатлары турында сөйләргә мөмкин.

Идеологик берләшүләр турында республиканың мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллинның да әйткәне бар. «Ватанпәрвәрлек, Ватанга мөнәсәбәт, аңа карата мәхәббәт тәрбияләү өлешенә – идеологик тәрбиягә игътибар итәр вакыт җитте, шуңа да оешма кирәк», – дигән иде ул бер вакыт.

Ә менә «Тәртип» радиосы башкарма продюсеры Айваз Садыровның идеология дигәннән фикере мондыйрак:

– Ниндидер оешма булдырып, идеология булдырып, шуны маяк итеп куюга караганда да гасырлар буе сыналган иң яхшы ысул – дин. Идеология ул һәрвакыт заман сулышына, заманга иярә һәм үзгәрә. Шул ук пионерия идеологиясен телгә алыйк. Әмма аларның гомере һәрвакыт чикле. Үз дәвере белән алар юкка чыга. Ә дин – әхлак, тәрбия якларын да исәпкә алган, тормышны күзаллауга, тормыш сорауларына җавап бирерлек чын мәгънәсендә дөрес юл. Балаларга шул тәрбияне бирү кирәк. Ул вакытында сеңдерелсә яхшы. Куркытып, мәҗбүриләп түгел! Үрнәк-мисаллар кирәк. Бу очракта бала моны үзенең тормыш кануны, фәлсәфәсе итеп кабул итәчәк, гомер буе шуңа тугры булып калачак. Дин тәгълиматлары буенча тәрбияләнгән балалар күбрәк булган саен, җәмгыять тә шулкадәр чистара.

«Бөтенесе дә Вәли булмас»

Бу уңайдан яшьләр үзләре нинди фикердә соң? Бер калыпка салынырга, бер төрле тәрбияләнергә телиме алар? Әллә булган оешмалар да җитеп торамы? Шул хакта кызыксындык.

Барысын да бер көймәгә куып кертеп булмас. Ясалма интеллект проектлары координаторы, «Россия – Ислам хезмәттәшлеге оешмасы» халыкара яшьләр хезмәттәшлеге проект офисы администраторы Тимерхан Шәйхетдинов шундый фикердә.

– Дөньякүләм тенденцияләргә, безнең илдәге процессларга карап, идеологиянең төрле булуы, аларның барысы да закон кысасында, әхлакый кагыйдәләргә туры килүе мөһим. Барысын да бер идеологиягә китерү, әлбәттә, яхшы. Әмма шул идеология тарафдары булырга теләмәгән кешеләрне дә онытмаска бит. Бөтенесе дә Вәли булырга теләмәс. Барысын да бер көймәгә җыеп булмас, – дип саный яшь егет. – Чынлыкта, безнең илдә, республикада күп кенә балалар һәм яшьләр өчен оешмалар нәтиҗәле эшчәнлек алып бара, үз идеологиясен төзергә тырыша. «Сәләт», «Йолдызлык», «Россия мәктәп укучылары» хәрәкәте, дисеңме. Турысын әйткәндә, аларның бер-берсе белән элемтә булдырып, эшләп торуы әһәмиятле. Әйтик, баланың бер хәрәкәттә катнашып, вакыт узу белән икенчесенә күчүе. Яшьләрне идеологик юнәлештә тәрбияләргә кирәк, әлбәттә. Дөресен әйткәндә, үзем дә заманында шактый гына балалар оешмаларында катнашып йөргән идем. Хәзер дә балалар иҗтимагый хәрәкәтен үстерү кирәк. Бу – алар өчен фикер белдерү урыны да. Шик юк, олы тормышка әзерли торган мәйданчык та – нәкъ шул. Кешеләр белән эшләү, җитди мәсьәләләрне хәл итү кебек сыйфатларны шул оешмаларда үзләштереп була.

Яшьләр хәрәкәтен берләштергән, системалаштырган бердәм оешма булса яхшы. Активист кыз, «Шаян ТВ» каналы алып баручысы Зилә Хәбибуллина менә шул хакта хыяллана.

– Идеология – бик четерекле, үзенчәлекле мәсьәлә ул. Без, XXI гасыр яшьләре дә, шундый. Безне элек булган хәрәкәтләр белән генә тиз арада күтәреп булмас. Әлбәттә, тарихны онытырга ярамый. Тик аны кайтарырга да кирәкми. Ә менә яшьләр хәрәкәтен системалаштырган оешма булса шәп! Бу оешманың үз кануннары, кагыйдәләре булуын телә идем, – ди Зилә. – Миңа хәзер эшчәнлек алып барган иҗтимагый хәрәкәтләр дә бик ошый. Алар үзенчәлекле. 2021 елдан Татарстанның балалар оешмалары советы рәисе булып торам. Республикадагы барлык балалар оешмалары белән эш алып барабыз. Эш белән беррәттән үзебезне бер гаилә дип саныйбыз.

Гомумән алганда, яшьләрнең идеологиясе бармы соң ул? Практик психолог, психология фәннәре магистры Зөһрә Кәримова, бар, әмма үзгә ул, дигән фикердә.

– Хәзер яшьләрдә идеология шундый ки, аларга белем алу да алай ук кызык түгел. Күбрәк бизнес кызыкты-ра, алар үз-үзләренә эшләргә тели. Шул рәвешле күбесе: «Ә укырга кирәкме?» – дип уйлый. Эчке максатларга килгәндә, яшьләр күп нәрсәгә җиңелрәк карый. Университетта укудан тыш та үзеңне камилләштереп, белем алып була икәнен яхшы аңлыйлар. Куркулары да бар инде. Мин моны шәхси тәҗрибәмнән дә әйтә алам. Әмма шуны күзәткәнем бар: нәрсә телиләр, шуны эшлиләр, кая барырга телиләр, шунда баралар. Хәзер үсмерләр дә телефон-гаджетлар белән күбрәк дус. Аларны мәгълүмати технологияләр тармагы, цифрлашу өлкәсе кызыксындыра, – ди белгеч.

Юксыну

Яшьләр тарихны онытмау һәм яңалык яклы булса, өлкән буын яшьлеген сагыну белән тиңли ул идеологиягә корылган хәрәкәтләрне. «ВТ»ның социаль челтәрләрендәге хатирәләр дә шуны дәлилли.

«Мин дә пионер булдым!» – дип горурланып әйтә алам. Ул вакытта да кайбер балаларда шуклык бар иде, ләкин без бер-беребезне, укытучыларны чын күңелдән хөрмәт итә идек. Шулай булмыйча – уку авыррак бирелгәннәргә дәрестән соң калып булыша идек. Хәлдән килмәсә, укытучылар булышты. Бушка! Бар да әйбәт булыр дип, без чын күңелдән киләчәгебезгә ышана идек», – дигән истәлеген язып калдырган Нурия ханым Закирова.

Рәшидә Фәхриева исә хәзер пионериягә охшаш оешманың булмавы үзен бик сиздерә дигән фикерен язып калдырган: «Ул октябрят, пионер, комсомол булуы ничек күңелле иде! Өстә җаваплылык тоя идек. Укытучы кушкан эшне 100 процент белән үтәргә тора идек. Малайларны пионердан, комсомолдан төшерәбез дигән куркыту кырын эшләрдән тыеп торды. Ул галстук тагу ямь өсти иде мәктәп формасына».

Раушания Солтанова: «Пионериянең бер зыяны юк. Барлык партияләр дә хуплар иде. Балаларның да бер ышанычлы партиясе булыр иде», – дип саный.

P.S. Шунысын да әйтми калу дөрес булмас. Үсеп килүче буын белән эш алып барырга телиләр икән, идеология белән дөньяга караш (мировоззрение) төшенчәләрен бутамыйча, кушмыйча эшләргә кирәк. Идеология – барыбер дә мәҗбүриләп тагыла торган күренеш ул. Ул барысына да бармаска мөмкин. Ә менә дөньяга карашны формалаштырырга ярдәм итү – бөтенләй башка мәсьәлә. Анысы өчен бездә үрнәкләр юкмы әллә?

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сан

- Росмолодежь мәгълүматларына караганда, хәзерге вакытта төрле хәрәкәтләргә һәм оешмаларга җәлеп ителгән балалар саны **3–5** млн кешегә җиткән. Ә мәктәпләрдә укучылар саны – **18** млн. Реестрдагы иҗтимагый хәрәкәтләр саны – **310.**
- Соңгы **30** елда ил күләмендә балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр өчен иҗтимагый хәрәкәтләр саны бермә-бер артты. Татарстанда гына да аларның саны – **750.**

3 июнь сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Лилия Гыймазова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Сабантуй булмыймы?

– Арча районындагы туган авылым Кушлавычтан чыгып киткәнемә 29 ел инде. Әти-әнием, туганнарым, апам шунда яши, укытучы булып эшли. Елга бер тапкыр гына булса да, авылдашлар, сыйныфташлар белән очрашасы килә. Элек Сабантуйда гөрләшә идек. Биш ел инде бу бәхеттән мәхрүм без. Дөрес, соңгысында бирнәләр җыеп, үзебез оештырган идек. Шуннан бирле авылыбыз тынып калды.

Кушлавыч Утар Аты авыл җирлегенә карый. Бездән 6 чакрым ераклыкта. Анда барырга кунакка кайткан һәркемнең машинасы бар инде барын. Әмма ул туган авыл түгел бит. Югыйсә, авылыбыз кечкенә булса да, 9 еллык мәктәбебез, музей эшләп тора. Сабантуйны да авыл халкы белән бергәләп оештырыр идек. Әби-бабайлар, балалар өчен бик кирәк бит ул.

Фәридә ШАҺИЕВА

Арча районы башлыгы урынбасары Алсу Мөхәммәтова:
– Татарстан буенча указ чыгып, Сабантуй көннәре билгеле булгач та, без барлык авылларга хәбәр җибәрдек. Бу бәйрәм өчен бюджетта акча каралмаган. Шуңа күрә үткәрү-үткәрмәү мәсьәләсен җирлек башлыгы халык белән хәл итә. Әгәр авыл кешеләре оештыручылар тапса, әйдәгез үткәрәбез дип, инициатива белән чыкса, кумәкләшеп эшкә тотынсалар, берникди каршылык та юк. Бүгенгә әле Сабантуй үткәрү көннәренең төгәл графигы да юк. Җирлек башлыкларыннан хәбәр көтәбез.

Редакциядән. Фәридә ханым да нәкъ шундый теләген җиткергән иде бит. Авыл халкы белән бергәләп оештырыр идек, диде. Баксаң, мондый теләккә каршылык та юк икән. Бәлки әле авылга инвестор булып килгән Рәфыйк Хөснетдинов та уянып китәр. Аңа да авыл халкының берләшүе, бердәм булуы кирәк бит инде югыйсә.

Ник болай бу?

– 29 мартта Балык Бистәсендә Октябрьнең 60 еллыгы исемендәге урамның 6 нчы йортында комендант булып эшли башлавыма 20 ел булды. 2020 елда «Безнең ишегалды» программасы буенча ремонт ясалды. Аңа бит инде акча да булеп бирәләр, проекты да бар. Әмма подрядчылар киләләр дә, ничек арзанракка төшә, шулай эшләп китәләр. Бу бит – халыкка зыян ясау дигән сүз. Безнең бистәдә 5 катлы, 80 фатирлы йорт бердәнбер. Мин шунда яшим дә һәм эшлим дә. Башта бөтен документларны әзерләп бирдем. Әэшне тапшырганда минем имзам бөтенләй кирәкми булып чыкты. Шулай буламы икәнни ул? Нәтиҗәдә, минем әйтүләремә, карточкага төшереп җибәрүләремә карамастан, 1–2 нче подъездларга керә торган урыннар тәбәнәгрәк калды. Көз көне яуган яңгырлардан ук су җәелде. Хәзер дә Байкал күленнән ким түгел. 16 май көнне район башлыгына бардым. «Башлаганын бетермәгән килеш ник аларга акчасе эш бирәсез?» – дидем. Подрядчыларның үзләре белән сөйләшкән идем. Асфальт утырды, диләр. Димәк, асфальт утырмасын өчен, нигезен дөрес итеп салырга кирәк булган бит инде.

Безнең йорт янынаннан дача участоклары башлана. Якшәмбе көн иде. Йорт башыннан 50–60 м җирне экскаватор казый башлады. Казылган җирне машиналар алып китеп бара. Бардым. «Ник казыйсыз?» – дим. «Безгә нәрсә кушсалар, шуны эшлибез», – дип җавап бирделәр. Бөтен җитәкчеләргә шалтыратып чыктым. Трубканы алмыйлар. Якшәмбе бит инде, ял итәләрдер. Идарәче компания җитәкчесе Бочаревка элемтәгә чыктым. Сез шалтыратып карагыз әле, минем телефонны алмыйлар, дим. Шуннан район башкарма комитеты рәисе белән килеп киттеләр. Дөрес казылмаган икән дип, эшне туктаттылар. Казылган урынны рәтлибез, дигәннәр иде, бүгенгә кадәр берни эшләгәннәре дә юк. Яз җиткәч, дача хуҗалары интегә башлады. Казылган җир сазга әйләнде, хәтта резин итекләр белән дә кереп булмый.

Узган ел декабрь башында, Казаннан килеп, ишегалдына ясалган ремонтны кабул иткәннәр иде. «Бу килеш һич кенә дә калдырырга ярамый, эшләп бетерергә кирәк», – дидем. «Ярый, хәзер соң инде, киләсе елга эшләрбез», – диделәр. Күреп торам: бер нәрсә дә эшләргә җыенмыйлар. Балык Бистәсендәге җитәкчеләр белән элемтәгә чыгудан берникди дә файда юк. Алар барысын да беләләр инде.

Хөрмәт белән, Раилә апагыз ДУДКО. Балык Бистәсе

Айгөл Солтанова

Редакциядән. Раилә апаның гадел, халык мәнфәгатьләре өчен тырышып йөрүче кеше икәнен инде күптәннән беләбез. Бу юлы да ул көрәшкә күтәрелгән булып чыкты. Тик, Балык Бистәсендәге җитәкчеләргә шалтыратудан мәгънә юк дисә дә, без эшне тамырдан башларга булдык: район башкарма комитеты җитәкчесе Марс Магизов белән сөйләштек. Ул Раилә апа күрсәткән җитешсезлекләрне кире какмады. «Башта ук шуны әйтеп куям: Раилә апа ашыга ул. Бу эшләрне гарантия буенча без барыбер эшлибез. Берникди проблема да юк», – диде. Бераздан тагын шалтыратты. Проект буенча эшләүче подрядчы оешма «Русремстрой» компаниясе юлчылары белән бу хакта кабат сөйләшкән икән. Безгә түбәндәгеләрне җиткерде:

– Хәзер алар бистәнең үзәгендә, башка ишегалдында эшлиләр. «Техниканы күчереп йөрү – үзе зур мәсьәлә бит, җиңел эш түгел, бик чыгымлы да. Июль башында план буенча элек эшләгән тирәгә күчәбез. Берләттән, булдыра алганча, Раилә ханым язган кимчелекләрне дә төзәтербез», – дип вәгъдә иттеләр. Ишегалдында, чыннан да, проблемалар бар. Ике подъездда ишек төпләре электән үк түбәнрәк тора. Аны болай да булдыра алганча эшләп карадылар кебек инде. Яңгыр сулары ага торган корылмалар куйдылар. Шуңа күрә юлчыларны да гаепләп булмый. Ә йорт янындагы юлга килгәндә исә, дөрестән дә, бу җир ялгыш казылды. Проект тиешенчә карап бетерелмәгән. Шул сәбәпле өскә азрак кызыл балчык чыгып калды. Әмма анда рәсми төстә билгеләнгән юл юк. Халык үзе салган сукмак кына иде. Анысын да тәртипкә китерергә уйлап торабыз.

Җитәкченең сүзләренә ышанып карыйк. Шулай да мин Татарстан буенча «Безнең ишегалды» программасы кысасында тәкъдимнәр, шикаятьләр туплаучы сайт белән элемтәгә кереп, хатны җибәрергә әзерләп куйдым. Раилә апа белән элемтәдә торырбыз. Берникди яңалык та булмаса, тиз арада бозны урыныннан кузгатып җибәрергә кирәк булыр.

Бакча чиге кайда?

– Бакча участогын ызанлаганда, безнең кишәрлекнең бер өлеше элек-электән күршеләр биләмәсендә утыруы ачыкланды. Шуның аркасында бакчаны исәпкә куярга да мөмкинлек юк, шәһәр башкарма комитетыннан документ та ала алмыйбыз. Нишләргә дә белмибез.

Гәрәф СӨНГАТУЛЛИН. Чаллы

Росреестрның Татарстан Республикасы идарәсе матбугат хезмәте җитәкчесе Галина Галиуллина:
– Мөгаен, күршедәге участок кайчандыр ызанлаштыру планыннан башка гына рәсмиләштерелгән булгандыр. Башта күршеләрегез белән сөйләшеп карагыз. Бәлки, чикләрне билгеләү буенча билгеле бер карарга килә алырсыз. Бу эштә сезгә кадастр инженеры ярдәм итәр. Әгәр барып чыкмаса, судка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Моның өчен ызанлаштыру планын тапшырырга һәм чикләрне билгеләү турында гариза язарга кирәк. Күршеләрегез җавап тотучылар булачак.

Фикер

Озакламый халкыбызның йөзек кашы булган бәйрәме – Сабантуй! Без – тарихлы һәм көрәшле халык. Уңган-булганлыгын дөньяга таныткан, татар атларын да көндәлек тормышка кайтара алган олуг милләт. Тик, әйтергә кирәк, соңгы елларда Сабан туенда көрәш югала бара. Ул элеккеге чын «амфитеатр» дан башка җиргә күчерелде. Ә нинди урын иде бит! Ә хәзер барысы да бер мәйданда кайнаша.

2000 нче еллар башында Идел буе районындагы Каенлыкта җанатарларның тавышы ерактан ишетелеп тора иде. Хәзер тын гына утыралар. Димәк, бүген көрәш кенә түгел, бу спорт төрен яратучылар да кими бара дигән сүз.

Бүгенге массовканы, акча булса, Кировта да, Тулада да ясап була. Сабантуйны болай гадиләштерергә ярамый. Бу мәсьәлә уңай хәл ителсен иде. Көрәшне табигый урынына – «амфитеатр»га кайтарыйк. Милли бәйрәмебез мөбарәк, тормышларыбыз куанычлы, берләштерә торган вакыйгаларга, бәрәкәтле малларга бай булсын.

Ихтирам белән, Таһир ҺАДИЕВ, Дәүләт Советы депутаты

* * *

Сугыш чоры балаларына быел да игътибар булмады. Акча юк түгел бит. Спортка күпме түгәләр, тик файдасы гына юк, гел җиңеләләр. Берәр мең тәңкә акча өләшсәләр дә, күңел булыр иде. Аның бит искә алулары кыйммәт. Хәер, акчасы да бик кирәк инде. Хәзер миңа – 82 яшь. Аена 13–14 мең сумлык дару гына эчәм.

Фәнис МӘҮЛИЕВ. Мөслим

* * *

Газета-журналлар өйгә килеп кергән кунак кебек. Алар үзләре белән ил яңалыклары, кызыклы фикерләр, күңелле, кайчак гыйбрәтле дә хәбәрләр алып киләләр. Ә менә шушы байлыкны вакытында китереп җиткерүчеләр – хат ташучы кызларыбыз. Сүзем Арча районы Яңасала авыл почта бүлекчәсендә эшләүче кызлар Нурия апа һәм Фиделя хакында. Яңасала һәм Каенсар авыллары халкы аларга бик рәхмәтле. Аларга бик күп төрле вазыйфалар ышанып тапшырылган. Җилкәсенә аскан авыр сумкада нигәр генә юк: газета-журналлар, хатлар, телеграммалар, утка-суга, газга, торак өчен түләргә тиешле квитанцияләр... Пенсия, субсидия тарату да – аларның вазыйфасы хәзер. Һәр йортка кереп, вакытлы матбугатка да яздырып йөриләр. Моң-зарларны да тыңларга туры килә кайвакыт. Тагын бер эш йөкләнгән әле: ул да булса – вак-төяк әйберләр белән сату иту. Бүгенге хат ташучы – авылның тоткасы ул.

Фәридә БОРҺАНОВА

* * *

«Ватаным Татарстан» журналисты Гөлгенә Шиһаповаһың өлгерлегенә кайчагында аптырап та куям. Кайда нинди фаҗигә булган, кем ятим калган, кем авырып киткән – кайдан белеп бетерә дә, элемтәгә кереп, ни арада ярдәмгә ашыга дигән. Бервакыт миңа якшәмбе көнне шалтырата. «Туган авылыгыз Югары Стәрледә Хөҗҗәтова фамилияле ханым әбине янгыннан коткарган икән. Шушы батырлыкны тулырак яктыртырга иде», – ди. Үзем ишетеп тә өлгермәгән идем әле.

Минем кебек читтән язып ятучы хәбәрчеләр белән дә гел элемтәдә ул. Аның җылы сүзләре безгә көч-дәрт өсти. Рәхмәт яусын!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ. Азнакай

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

30 май | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА» 12+
10.00, 23.30 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА 2» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00, 03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00, 01.10 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Соотечественники» 12+
00.45 «Каравай». Плодовый сад великого русского писателя 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Ватандашлар». Урманнан сузылган җыр. Зилә Сөнгатуллина 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның атказанган артисты Илдус Габдрахманов турында телеочерк 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Дмитрий Дюжев, Екатерина Гусева, Евгений Дятлов, Дмитрий Назаров, Александр Лазарев. «ТОБОЛ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «АнтиФейк» 16+
00.25 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.45 «ВЕРСИЯ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 08.45, 12.30, 18.20 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.50, 12.35, 03.10 Специальный репортаж 12+
09.10 Хоккей. Чемпионат мира. Финал. Трансляция из Финляндии 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 Регби. Чемпионат России. «Красный Яр» (Красноярск) – «Локомотив-Пенза». Прямая трансляция
14.55 Хоккей. Международный турнир «Кубок Чёрного моря». Финал. Прямая трансляция из Сочи
17.20 Автоспорт. Российская Дрифт серия. Гран-при 2022. Трансляция из Нижнего Новгорода 0+
18.25 «Громко». Прямой эфир
19.30 Баскетбол. Единая лига ВТБ. Финал. ЦСКА – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
21.55 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.30 Тотальный футбол 12+
01.00 «АНДЕРДОГ» 16+
03.25 Новости 0+
03.30 Классика бокса. Мохаммед Али. Лучшее 16+
04.15 Классика бокса. Джордж Форман. Лучшее 16+
04.35 Классика бокса. Майк Тайсон. Лучшее 16+
05.00 «Громко» 12+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.30 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Сергей Жарков. «ДЕЛЬФИН» (S) 16+
23.30 «ПЁС» (S) 16+
02.45 «Таинственная Россия» 16+
03.30 Остросюжетный сериал «ШАМАН» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «Чудотворица» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Месть за отца» 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «СЕМЕЙНЫЕ ТАЙНЫ» 16+
19.00 «ПАПА ДЭН». 1-я – 4-я серии 16+
22.45 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4». 1-я и 2-я серии 16+
00.30 «Понять. Простить» 16+
01.20 «Порча» 16+
01.45 «Знахарка» 16+
02.10 «Верну любимого» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.05 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.15 «СТРЕЛЯЮЩИЕ ГОРЫ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30, 23.15 «СУМКА ИНКАССАТОРА» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 14.05 «Истребители Второй мировой войны». Док. сериал 16+
14.00 Военные новости 16+
14.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Между тем» 12+
22.25 «Загадки века». Док. сериал. «Кремлёвские пенсионеры» 12+
00.50 «ЧУЖАЯ РОДНЯ» 12+
02.25 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
03.50 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+

31 май | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 15.30 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА» 12+
10.00, 23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА 2» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
17.00 «Ватандашлар» 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 12+
19.00, 01.30 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Наби Даули. Я смотрю тебе в глаза 12+
00.50 «Каравай». Тайный смысл народных сказок 6+
01.15 «Не от мира сего...» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Әхәт Гаффар турында телеочерк (субтитрлы) 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ТОБОЛ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «АнтиФейк» 16+
00.25 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.45 Виктория Полторак, Павел Крайнов, Кирилл Болтаев. «ВЕРСИЯ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 08.45, 12.30, 14.55, 18.20 Новости
06.05, 17.30, 20.30, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.50, 12.35, 03.10 Спец. репортаж 12+
09.10 «АНДЕРДОГ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55, 15.00 «КИКБОКСЁР ВОЗВРАЩАЕТСЯ» 16+
15.20 «САМОВОЛКА» 16+
18.25 Легкая атлетика. Мировой континентальный тур. Прямая трансляция из Чехии
21.00 Профессиональный бокс. Харитон Агрба против Авака Узляна. Прямая трансляция из Москвы
00.40 «Есть тема!» 12+
01.00 «В ЛУЧАХ СЛАВЫ» 12+
03.25 Новости 0+
03.30 «Диалоги о рыбалке» 12+
04.00 «Правила игры» 12+
05.00 Легкая атлетика. Мировой континентальный тур. Трансляция из Чехии 0+

НТВ
05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.30 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Детектив «ДЕЛЬФИН» (S) 16+
23.30 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
02.45 Их нравы 0+
03.20 Остросюжетный сериал «ШАМАН» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Навязанная любовь» 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «ПАПА ДЭН». 1-я – 4-я серии 16+
19.00 «ПАПА ДЭН». 5-я – 8-я серии 16+
22.45 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4». 3-я и 4-я серии 16+
00.35 «Понять. Простить» 16+
01.25 «Порча» 16+
01.50 «Знахарка» 16+
02.15 «Верну любимого» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25, 18.45 «Специальный репортаж» 16+
09.45, 23.15 «БЕРЕМ ВСЕ НА СЕБЯ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 14.05 «Истребители Второй мировой войны». Док. сериал 16+
14.00 Военные новости 16+
14.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+
22.00 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
22.25 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
00.35 «КАРАВАН СМЕРТИ» 12+
01.50 «ЧУЖАЯ РОДНЯ» 12+
03.25 «Москва фронту». Док. сериал 16+
03.50 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 30 МАЙ – 5 ИЮНЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Катлаулырак атна. Эш күп өелгәнлектән, кайсына тотынырга белмичә аптырап калырга туры килер. Әле ярый дустыгыз килеп туган хәлдән дөрес итеп чыгу юлын күрсәтер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Көч-куәтегез ташып торган чор. Ләкин теге яки бу мәгълүматларга бик сак карагыз, юкса белер-белмәс килеш ялгышлык эшләп ташлавыгыз бар. Атна ахырында әйбәт кенә керем алачаксыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Эштә дә, шәхси тормышта да – кызыклы, уңышлы чор. Хезмәттәшләрегездән үзгәрәк фикер йөртүегез четерекле бер мәсьәләнең очына чыгарга ярдәм итәр. Кемнәрдер сезнең уңышка эчкерсез сөенер, ә кемнәрдер, киресенчә, көенер...

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Хезмәт урынында күп аралашырга, телефоннан бертуктаусыз диярлек сөйләшергә туры килер. Бу хәл шактый ук алҗытса да, алга таба әйбәт кенә бер уңышка ирешүгә җирлек тудырыр. Тагын да мулрак тормышка өметләндерердәй яңалыклар ишетелер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Тормышыгызда бик әйбәт чор җитеп килә. Аны «яңа этап» дип тә бәяләргә мөмкин хәтта. Нәрсәләрнедер үзегезчә эшләү өчен искитмәле дәрәҗәдә уңайлы мөмкинлекләр ачылыр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Атна башында, ыгы-зыгыдан туеп, беравык ялгызлыкта калып тору теләге туар. Эштә авыррак хәл килеп чыгар. Әмма эчке сиземләвегез судан коры чыгарга ярдәм итәр. Бер танышыгыз әйбәт кенә хәбәр белән куандырыр.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Эшегездә иркенлек сизелә башлар. Бу тормышыгызда үзенә бер җиңеллек, рәхәтлек китерер. Дусларыгызның ярдәменнән йөз чөермәгез, әмма аларга бөтенләй үк ышанып та бетмәгез.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Атна башына билгеләнгән шәп кенә планнарыгыз үзегез көткәннән дә яхшырак үтәлер. Өйне кирәкмәс иске-москыдан чистартыгыз: тормышыгызга уңай үзгәрешләр үтеп керсен өчен шулай кирәк. Ял көннәрендә үзегезне чиксез бәхетле итеп тою өчен сөеклегезнең бер сүзе дә җитәчәк.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Беркем дә хатадан хали түгел. Бу атнада шул гыйбарәне искә төшерергә туры килер. Хуш, сезгә аның, зыяныннан бигрәк, файдасы күбрәк булыр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Аз-маз кыенлыклар алдында каушап калмасагыз, шәп кенә нәтиҗәгә ирешерсез. Эш алыштыру турында уйлар пәйда булырга мөмкин. Әмма «без булмаган җирдә яхшы» дигән сүзләрне искә төшереп, башыгызга килгән уйларны тизрәк куып җибәрергә тырышырсыз.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Ялгызларга үз парларын табу өчен менә дигән форсат чыгар. Гомумән, бик матур танышулар, гадәти булмаган тәэсирләр алу, сөенеп яшәү чоры. Карьера баскычыннан югарырак күтәрелү мөмкинлеге дә ачылыр кебек әле.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Атна башында әйбәт яңалыкларга сөенерсез. Эшлекле тәкъдим була икән, баш тартмагыз. Барысына да көчегез җитәчәк!

КОТЛЫЙБЫЗ!

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Казан утлары» журналы редакциясе» филиалы баш мөхәррире – җитәкчесе **Галиуллин** Рөстәм Госман улына; «Татарстан Республикасының Бокс федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Игнатьев** Сергей Михайловичка; «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле артисты – солисты-инструменталисты **Мәүлетов** Роберт Кирам улына; Татарстан Республикасының «Чаңгы ярышлары һәм биатлон федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы сервисмены-автомобиль йөртүчесе **Адылев** Сергей Владимировичка; Татарстан Республикасының «Чаңгы ярышлары һәм биатлон федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы баш бухгалтеры **Титова** Елена Викторовнага; Татарстан Республикасының «Чаңгы ярышлары һәм биатлон федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы сервисмены **Феллер** Максим Александровичка; Татарстан Республикасының «Чаңгы ярышлары һәм биатлон федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы спортчысы **Филимонов** Денис Александровичка; Татарстан Республикасының «Чаңгы ярышлары һәм биатлон федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы өлкән тренеры **Ходырев** Дмитрий Сергеевичка; Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Әскәров** Ралиф Рафикъ улына; «Татарстан Республикасы техник инвентаризация бюросы» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: мәгълүмат технологияләре бүлеге башлыгы **Игнатьев** Александр Владимировичка; Казан бүлегенең Зеленодольск бүлекчәсе җитәкчесе **Пахмутова** Елена Юрьевнага; Чаллы филиалының Минзәлә бүлекчәсе җитәкчесе **Петрова** Татьяна Ефремовнага; техник директор **Хәбибрахманов** Радик Рәфит улына; генераль директор урынбасары **Хәйруллина** Ольга Владимировнага; генераль директор **Хәмзина** Лена Илдар кызына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ҖӘЙ ҖӘРӘХӘТСЕЗ УЗСЫН

Зарыгып көткән җәй еш кына имгәнү-җәрәхәтләре белән дә истә кала. Аяк астыннан чыккан бәлаләр дә күбрәк шул вакытта килеп чыга, ди белгечләр. Бүгенге сәхифәбездә беренче ярдәм күрсәтү кагыйдәләрен искә төшерәбез.

КОЯШ СУГУ

▶ **Билгеләре.** Кояш суккан кешенең башы авырта, хәлсезләнә, коса, температурасы күтәрелә, колагы да шауларга мөмкин.

➞ **Нәрсә эшләргә?** Хәле начарланган кешене иң элек тизрәк күләгәгә яки салкынчарак урынга алып чыгыгыз. Башын югарырак күтәртеп яткырыгыз. Кысып торган киемнәрен салдырырга яки чишеп җибәрергә кирәк. Авыруның өстенә салкын су сибегез, юеш җәймә белән төреп куегыз. Маңгай турысына салкын суга манылган чүпрәктән компресс куегыз. Аңында булса, авыруга күп итеп су эчерегез. Күңеле болгана башласа, аны яны белән яткырыгыз. Бармакка бинт урап, авыз куышлыгын чистартыгыз. Косык үпкәгә эләгергә тиеш түгел. Кеше аңын югалткан очракта, нашатырь спиртына манылган мамык иснәтеп, аңына китерергә кирәк. Кешенең сулышы тоемланмаса, йөрәкнең тибеше сизелмәсә, йөрәккә массаж ясарга һәм ясалма сулыш алдырырга кирәк. Авыруга үзегез генә ярдәм итә алмасагыз, кичекмәстән табиб чакырыгыз. Кечкенә балага эссе сукканда; зыян күрученең тән температурасы 39 градуска кадәр күтәрелгәндә; кеше берничә минут дәвамында аңсыз ятса, сулавы кыенлашса; борыныннан кан китеп, 5 минут эчендә туктамаса, иң беренче чиратта табиб чакырырга кирәк.

БАЛ КОРТЫ ЧАГУ

▶ **Билгеләре.** Корт чаккан урын, гадәттә, шешеп чыга, кычыта. Кайбер кеше корт агуына аеруча нык сизгер була. Андый чакта аларның тәннәренә кычыткан бизгәге (крапивница) чыга, өске сулыш юллары, бронхлар кысылып, кеше буыла башлый, кан басымы төшәргә мөмкин.

➞ **Нәрсә эшләргә?** Иң беренче эш итеп энәсен чыгарып, яра урынын эшкәртергә кирәк. Корт чагудан аллергиясе булган кешегә исә тиз арада беренче ярдәм күрсәтелергә тиеш. Авыруны иң элек яткырып, бүлмәне җилләтергә, буылса, ясалма сулыш алдырырга кирәк. Кортның энәсен пинцет ярдәмендә алырга, зыян күргән урынга боз куеп торырга яки спирт катнашмасы белән эшкәртергә, антигистамин дарулар эчәргә, преднизолон мазе сыларга кирәк.

СУГА БАТУ

▶ **Билгеләре.** Сулыш юлларына су эләгү аркасында кешегә һава җитми башлый, буыла, суда тыпырчынырга тотына.

➞ **Нәрсә эшләргә?** Суга батканда кеше куркудан теләсә кайсы әйбергә тотынырга тырышачак. Андый чакта кул астына коткаручы эләксә, икегезнең дә гомеренә куркыныч яный дигән сүз. Шуңа күрә суга батучы янына арттан йөзеп килеп, аны чәченнән яки култык астыннан эләктереп алырга кирәк. Алга таба аның йөзен өскә каратып, яр кырыена алып чыгу зарур. Суга батучының сулышы сизелмәсә, тиз арада аркасына яткырып, йөрәгенә массаж ясагыз. Үз аңында булган очракта, юеш киемнәрен салдырып, коры киемнәр киертергә, җылы чәй эчерергә кирәк.

СӨЯК СЫНУ

▶ **Билгеләре.** Җәрәхәтләнгән кул яки аякны аз гына селкетергә маташканда да көчәюче кискен авырту сизелә. Сөяк сынуның иң беренче билгесе әнә шуннан гыйбарәт. Сөяк сынуның ачык һәм ябык төрләре була. Ябык сыну вакытында тире бозыла. Көчәрә үзгәрү һәм мускуллары кыскару нәтиҗәсендә, гадәттә, кул-аякның озынлыгы кечерәя. Шул сәбәпле тышкы яктан аларның формасы үзгәрә. Ачык сыну вакытында тән тиресе ертылып ук чыга. Кайчак хәтта сөякнең очы күренеп торырга да мөмкин.

➞ **Нәрсә эшләргә?** Иң элек сынган урынга кул астындагы таяк, такта яки эре ботаклар ярдәмендә шин салыгыз. Җәрәхәтләнгән очлык мөмкин кадәр азрак хәрәкәтләнерлек булсын. Сынган кул-аякны яулык, шарф, каеш ярдәмендә ике күрше буынны шин эләктерерлек итеп салыгыз. Әйтик, балтыр сөяге сынган вакытта шинны тез һәм балтыр-табан

pixabay.com

буыннарын эләктереп салырга кирәк. Болай эшләгәндә алар хәрәкәтсез булачак, сөяк сыныклары, тирә-яктагы тукымаларны җәрәхәтләп, күчә алмаячак. Имгәнгән ботка шин салганда аеруча игътибарлы булырга кирәк. Әгәр якын-тирәдә шинга аз гына булса да охшаган бернәрсә дә юк икән, зыян килгән аякны бинт ярдәмендә икенчесенә бәйләп куегыз. Иңбаш сөяге сынган вакытта кулны гәүдәгә бәйләп кую киңәш ителә. Шуннан соң гына зыян күрүчене хастаханәгә озатырга мөмкин.

БӘРЕЛҮ

▶ **Билгеләре.** Бәрелгән урын сызлый башлый, шешеп чыга. Берничә сәгатьтән бәрелгән урында кара көйгән эз дә пәйда була. Тирән тукымалар җәрәхәтләнгәндә ул урын 2–3 көннән соң да каралып чыгарга мөмкин.

➞ **Нәрсә эшләргә?** Башта бәрелгән урынга кысып торучы бәйләвеч салып, аны бозлы куык, салкын компресс, юеш тастымал, салкын металл әйбер ярдәмендә суытырга кирәк. Алга таба бәрелгән аяк-кулны өчпочмаклы яулыкка асып куеп, буынны 8ле кебек бәйләвеч, шин ярдәмендә бәйләргә. Күгәргән урын тизрәк суырылсын өчен, тирегә 0,25–0,5 процентлы йод эремәсе белән «челтәр»ләр ясарга мөмкин. Моның өчен 5 процентлы йод эремәсен спирт яки аракы белән сыеклатырга кирәк. Баш, күкрәк һәм корсак бәрелгәндә яшерен җәрәхәтләр барлыкка килергә мөмкин. Бу очракта кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Бәрелү урынында барлыкка килгән күгәректәге үзгәрешләрне дә күзәтеп тору хәерле. Әгәр ул вакыт узган саен төсен кызылдан – аксыл шәмәхәгә, чия кызыл һәм зәңгәргә, аннары саргылт-яшелгә үзгәртә икән, димәк, барысы да тәртиптә.

КУЛ, БАРМАК КИСЕЛҮ

▶ **Билгеләре.** Кул, бармак киселүне гадәти күренеш итеп кабул итәргә күнеккән без. Әмма киселгән урын сызласа, тән тиресе агарса, маңгайдан тир бәреп чыгып, бизгәк башланса, кан агуны туктатып булмаса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

➞ **Нәрсә эшләргә?** Киселү артык тирән булмаса, иң элек аны җылы су белән юып алырга кирәк. Алга таба киселгән урынның кырыйларын (яраның үзен түгел!) хлоргексидин, водород перекисе, йод яки яшел су (зеленка) белән эшкәртегез. Аннары яра өстенә пластырь ябыштырасы.

Нинди дару үләннәрен җыярга?

✓ **Үги ана яфрагы** салкын тию, грипп, сулыш юллары чирләреннән бик файдалы. Дәвалану өчен чәчәкләре һәм яфраклары кулланыла. Чәчәкләрен – майда, яфракларын июньдә җыялар.

✓ **Тузганак** витаминнар, калий һәм фосфор тозларына бай. Тәнәтмәсе организмны ныгыта, тынычландыра, канны чистарта, лимфа системасы ялкынсынудан ярдәм итә, организмны яшәртә, азканлылыктан файдалы.

✓ **Бака яфрагы** җәрәхәтләрне тиз төзәтә. Киптерелгән яфрак шешләрне киметә, какырыкны яхшы куптара, озакка сузылган ютәлне җиңәргә ярдәм итә.

✓ **Әрекмән.** Майда әрекмәннең тамырын һәм яшь яфракларын җыялар, ул онкология чирләреннән, ревматизм, буыннар сызлаудан кулланыла. Шешенү һәм варикоздан әрекмән яфрагы белән компресс ясарга була.

✓ **Кычыткан.** Май кычытканы бик шифалы, аны дәвалану өчен генә түгел, чирләрне кисәтү максатында да кулланырга кирәк. Ашын пешерегез, киптереп куегыз. Яшь кычыткан яфраклары үт суын куа, кан тамырларын киңәйтә, ялкынсынудан ярдәм итә, гемоглобинны, организмның тонусын күтәрә, иммунитетны ныгыта.

Абау!



Табиб-терапевт Стив Хруби бавыр авыруының төп билгеләрен атаган. Аның сүзләренчә, тән тиресе кычытуы, аяклар шешенүе һәм косасы килү куркыныч чир пәйда булу турында кисәтә.

«Тире кычыту – бавыр чиренең типик билгеләренең берсе. Аның сәбәбе төрле булуы мөмкин: үт куыгы юлларында ташлар, үт куыгы юллары яман шеше, ашказаны асты бизе шешенүе, беренчел билиар цирроз. Бавыр китереп чыгарган кычынуда тиредә еш кына тимгелләр яисә ярылар күзәтелми», – ди эксперт.

Бавыр чиренең тагын да киң таралган бер билгесе – ангиомалар. Биттәге һәм аяклардагы үрмәкүчсыман вак кан тамырлары бавырның тиешенчә эшләмәвен күрсәтүе мөмкин.

Буыннар шешенү, укшу, кан укмашу, кан агу шулай ук авыру хасил булуын күрсәтергә мөмкин. «Моның кан куелыгы өчен җавап бирүче билгеле төр аксымнар җитешмәүгә бәйле булуы мөмкин, бу бавырның дөрес эшләмәвен аңлата», – дип аңлата Хруби.

Аяк табаннары шешенү, талчыгу хисе бимазалавы, эч авырту һәм аның кабаруы, тире һәм күз агының саргаюы, сидек төсенең үзгәрүе, табиб әйтүенчә, шулай ук бавыр чире билгеләре булуы ихтимал. Табиб бу билгеләрнең барысына да җитди игътибар итәргә, диагнозны раслау яисә кире кагу өчен кичектермичә тикшерену үтәргә киңәш итә.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

РИЗЫК ӘЗЕРЛӘҮНЕ БӘЙРӘМГӘ ӘЙЛӘНДЕРӘ

Ул гап-гади ризык әзерләүгә дә бәйрәм төсмере өсти, якыннарны үз тирәсенә җыя. Анда пешергән ризыклар теләңне йотарлык була. Сүзебез үзенчәлекле мич – тандыр турында. Аны сайлау һәм куллану буенча тандыр сату белән шөгыльләнә торган кибет җитәкчесе Фәнил ГАЙФЕТДИНОВтан сораштык.

:: Бүген тандыр киң кулланыла. Аның ниндиләре була? Еш кунак җыярга яратучылар өчен кайсын сайларга киңәш итәр идегез?
– Тандырның кечкенәсе, уртачасы һәм зуры була.

КЕЧКЕНӘ ТАНДЫР. Ул мангал урынына үзең белән табигатькә алырга уңайлы. Аның авырлыгы 55 килограммга кадәр һәм ул якынча алты кеше өчен исәпләнгән. Тик әлеге тандырның кимчелекләре шунда: анда күп ризык әзерләп булмый һәм аксессуарлары аз булганлыктан, күп төрле ризык әзерләү дә мөмкин түгел.

УРТАЧА ЗУРЛЫКТАГЫ ТАНДЫР. Әлеге тандырда кечкенәсе белән чагыштырганда зуррак күләмле ризыклар әзерләргә мөмкин. Анда шампурда шашлык һәм яшелчәләр, рәшәткәсендә балык һәм ит калҗалары, тавык түшкәләре пешерергә була. Мондый тандырның авырлыгы 50–80 кг чамасы. Уртача зурлыктагы мич 6–10 кешелек ризык әзерләү өчен уңайлы. Ул җылыны кечкенә тандырга караганда озаграк, зурына караганда азрак саклый.

ЗУР ТАНДЫР. Монысында уртача зурлыктагы тандырда пешереп булган ризыклардан тыш тагын да зуррак күләмле булган бөтен каз һәм үрдәк түшкәләрен, зур кисәкле бәрән һәм сыер итен, күмәч, самса һәм чуенда теләсә нинди ризык пешереп була. Әлеге тандыр 10 кешедән артык кунак җыйганда уңайлы. Авырлыгы 80–200 кг чамасы.

:: Тандырда пешергәндә нинди агач ягу яхшырак?
– Иң яхшысы – каен. Аның бәясе дә кулайрак һәм җылыту үзлеге дә яхшы. Наратның яну температурасы – 600, ә каенныкы 800 градус. Каен агачы тизрәк яна һәм тандырны да тизрәк җылыта. Тагын да югарырак температура бирүче ул – имән. Аның яну температурасы 900гә җитә, әмма ул кыйммәтрәк йөри. Монда аерма әллә ни күп түгел, шунлыктан каен утыны яксагыз оттырмассыз.

Исеңдә тот!
- Артык суыну һәм җылынудан саклагыз.
- Ул артык дым яратмый. Яңгыр һәм кар явып торганда кулланмау киңәш ителә.
- Аны төшереп җибәрүдән, бәрелүдән саклагыз.
- Тандырда учак тергезү өчен газ горелкасы кулланырга мөмкин, аның белән тизрәк янып китәчәк.
- Ризык әзерләгәндә, бер төрле температураны сакларга тырышыгыз. Аны үлчәү өчен пирометр кулланыгыз. Тандыр 200 градуска кадәр җылынгач, димәк, ризыкны анда урнаштыра башларга вакыт дигән сүз.
- Утынны җаен бер сәгать, ә кышын бер сәгать ярым чамасы янарлык итеп өстән торырга кирәк.
- Тандырны суытам дип, салкын су сибәргә ярамый!

Тандыр – балчыктан ясалган мичнең бер төре. Анда ризык майсыз әзерләнә. Шулыктан ул күпкә файдалы һәм тәмле. Тандырның капкачын ачып та, ябып та пешерергә мөмкин.

:: Тандырда шашлыктан башка бик күп ризыклар әзерләп була икән...
– Тандырда туңдырмадан башка барлык ризыкны да әзерләргә мөмкин. Балык, ит, яшелчә, җиләк-җимеш, гөмбә, пицца, камыр ризыклары, бөтен каз, үрдәк һәм бәрән боты пешерергә була. Балык, иттән стейклар, яшелчәләр һәм гөмбә ише шампур белән пешереп булмый торган ризыкларны рәшәткәдә пешерергә мөмкин.

:: Тандырда пешергәндә әзер күмер кулланырга һәм яндырып җибәрү өчен махсус сыекчалар сиптерергә ярыймы?
– Күмер азык пешерү өчен кирәкле җылыны бирмәячәк, шунлыктан утын ягу яхшырак. Ә махсус сыеклыкларны кулланмавың хәерле, чөнки ул тандырның стеналарына һәм төбенә сеңәргә мөмкин.

:: Тандырга казан куеп кулланырга мөмкинме?
– Әлбәттә, аны казан кую өчен дә кулланып, рәхәтләнеп пылау яки аш пешерергә дә була.

:: Күпкатлы торак йортларның ачык террасаларында тандыр кулланырга рөхсәт ителәме?
– Юк, янгын куркынычсызлыгы максатыннан бу катгый тыела.

Тәмле булсын!

ЛЮЛЯ КЕБАБ

Кирәк булачак: 1 кг ит, 300 г сарык мае, 2–3 баш суган, үзегез яраткан тәмләткечләр, тоз. Бу порция 3–4 кешегә исәпләнгән.

Итне иттарткычтан чыгарып яки бик ваклап турап, аңа ваклаган май, туралган суган һәм тәмләткеч белән тоз кушып болгатырга. Аннары шарчыклар ясап, кебаб әвәләргә һәм шампурга тезәргә. Җылынган тандырга урнаштыргач, капкачын каплап, 15–20 минут пешерергә. Шампурны алып, әйләндереп торырга кирәкми.



ЖУЛЬЕН

Кирәк булачак: 500 г тавыкның түш ите, 200 г суган, 200 г уылган сыр, 250 г гөмбә, 300–350 г 15–20 процентлы сөт өсте (сливки), 2 аш кашыгы он, тәменчә тоз һәм борыч.

Пешкән тавык итен ваклап турарга. Майда кыздырылган суган өстенә пешкән тавык ите белән гөмбәне салып болгатырга. Он, сөт өсте, тоз салып, аерым савытта кайнатырга. Кайнап чыккач, суган белән ит өстенә салып болгатырга. Махсус савытына салып, өстенә уылган сыр сибеп, тандырның рәшәткәсенә урнаштырырга. 5–7 минуттан жульен әзер булачак.

УХА

Кирәк булачак: сөләйман балыгы (лосось), бәрәңге, кишер, суган, тоз, борыч, петрушка, укроп.

Балык кайнаган шулпага яшелчәләрне турап салырга. Тәменчә тоз, борыч өстәргә. Чуенга салып, капкачын каплап, аны тандырга урнаштырырга. 7–10 минут кайнагач, уханы алып, бераз тотканнан соң, яшел тәмләткечләр сибеп, табынга бирергә мөмкин.

Әгәр тандыр отасыгыз килсә, шартлары белән 20 биттә танышырга мөмкин >

Бакчачыга

Кыяр 3 л су «эчә»

Кыярны помидор кебек сусыз интектерергә ярамый. Чөнки ул шиңә һәм чәчәкләре коелып, бөтенләй уңышсыз калырга мөмкинсез. Кояшлы эссе көндә кыярның бер төбенә тәүлегенә 3 литр су сибәргә кирәк. Болытлы көнне дә су сипми калдырмагыз, бары суның күләмен генә бераз киметегез.

Дым җитәме?

Туфракта дым җитәме-юкмы икәнлеген тикшереп карауның бер җайлы гына ысулы бар. Моның өчен туракны 10–15 см чамасы казып, бераз туфрак алып, аны учыгызда кысыгыз. Әгәр туфрак укмашып торса, таралып китмәсә, димәк, туфракта дым җитә дигән сүз.

Матур бул!

Зелпе яшәртә

1 аш кашыгы изелгән зелпе җимешенә 2 аш кашыгы каймак яки кефир, 1 чәй кашыгы бал салып болгатырга. Әзер катнашманы биткә һәм декольте тиреләренә сөртергә. 15 минуттан соң җылы суда чылатылган тастымал белән сөртеп алырга һәм салкынча су белән юынырга. Тирегез тартылып, яшәреп һәм чистарып китәчәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КӨН ДӘ БЕР СОРАУ

Сәхифәбезне укучыларыбыздан килеп ирешкән сорауларга багышларга булдык.

Бу юлы да сорауларга җавап эзләп, Айморат хәзрәт ХАҖИЕВка мөрәҗәгать иттек.

? Яңгыр яуганда дога кабул була, дигәннәре дөресме?

АЛСУ

– Әлбәттә. Дөресрәге, яшен яшьнәгәндә. Яңгыр яуганда гына түгел, кешенең гамәлләре, тормышы матур, дөрес булса, аның ялварып сораган догасын Аллаһы Тәгалә кабул итәчәк, җавабын бирәчәк.

? Мәҗлестә «берне тотып куярга» ярата торган кешеләр белән бер өстәл янында утырырга туры килеп, алар исерткеч эчемлекләр эчсә, мин эчмичә дә гөнаһлы буламмы?

Исемемне күрсәтмәскә

– Гөнаһы була. Бу шушы кешеләргә охшау да санала. Динебездә бу тыелган. «Хәрам әйберләр дә, хәләл әйберләр дә билгеле, әмма алар арасында сезне гөнаһка тарткан сез белмәгәннәре дә бар», – диелә динебездә. Монда начарлыклардан иң яхшырагын эзлисең инде. Тугантумачалар җыелганда да барысы да дин-

dumrt.ru

дә булмаска мөмкин бит. Әйтик, бертуганың туйга чакыра, анда исерткеч эчемлек буласын беләсең, ди. Туганлык җепләре өзелмәсен дип, килеп, бәйрәм белән котлап китәргә мөмкин, монысы хәерле булыр.

? Ватык савыттан ашарга, эчәргә ярамый, диләр. Бу дөресме?

РАИЛӘ. Кайбыч

– Ырым-шырымга охшап тора бу. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләрендә бу хакта мәгълүмат юк. Әлбәттә, практик яктан, ярамый, чөнки ул синең сәламәтлегеңә зыян китерергә мөмкин. Иренең, кулың киселүе бар бит. Балалар кулына эләксә, шулай ук куркыныч. Шул яктан гына тыю бар. Аллаһ – яхшырак белүче!

? Намаз вакытында ялгышсаң, нишләргә? Бу гөнаһмы?

ФӘНИЛ. Буа

– Бу гөнаһ саналмый. Адәм баласы инсан өммәтеннән. Аңа ялгышу, онытылу хас. Хатадан берәү дә хали түгел. Намазның эчке һәм тышкы фарызлары бар. Әйтик, сәҗдәгә китү, басып «Фатыйха» сүрәсен уку, намаз вакыты һәм башкалар. Фарыз гамәлләр үтәлми икән, намаз бозыла. Бу очракта аны яңадан башлыйбыз.

? Тиздән беренче балабызны алып кайтырга җыенам. Бик куркам. Бала тапканда хәлне җиңеләйтә торган дога юкмы?

ЛӘЙСӘН. Казан

– Бала – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, җимеше. Әлхәмдүлилләһ, җиңеллекләрен бирсен. Дога дигәндә, бу – Коръәндәге «Зәкәрия» догасы. Ул болайрак яңгырый: «Рабби һәб лии мил-ләдүнкә зүррийййәтән таййибәтән иннәкә сәмиигуд-дугаа». Мәгънәсе: «Әй, Раббым! Миңа саф һәм пакь бер бала ихсан ит, шөбһәсез, Син – доганы ишетүче һәм кабул итүчесең». Әлеге доганы укый аласыз. Гомумән, Аллаһы Тәгаләгә ялварып, исән-сау баланы дөньяга китерергә язсын, дип сорап йөрергә мөмкин. Куркырга кирәкми! Аллаһ – үзе ярдәмче.

? Нинди су белән тәһарәт алырга ярамый?

АЛИЯ. Балык Бистәсе

– Суның исе, тәме, төсе исәпкә алынырга тиеш. Шул ук вакытта безнең суга нәҗес (пычрак) тигән булса, әйтик, бәвел, балчык, андый суны кулланырга ярамый. Суны хайваннар эчкән булса да, рөхсәт ителми. Әмма песи эчсә, ярый. Кыскасы, су чиста булырга тиеш.

? Диндә донорлык рөхсәт ителәме? Мәсәлән, акчага кан бирү?

Исемем редакция өчен генә

– Шөкер, хәзерге көндә медицина алга бара. Яңа дарулар уйлап табалар, элек дәваланмый торган чирләргә дәва чыгаралар. «Чир дә булыр, аннан дәвасы да бирелгәндер», – ди пәйгамбәребез (с.г.в.). Әгәр дә инде башка дәва чарасы булмаган, иң соңгы чик икән, шул вакытта донорлык рөхсәт ителә. Кан бирү дә исламда ярый. Әмма акчага түгел. Ислам динендә бернәрсә дә акчага эшләнми. Кешегә булышу Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен булырга тиеш.

? Килен кеше каенанасы белән каенатасына «әти-әни» дип әйтергә тиешме? Әти белән әни бер генә була бит ул.

ӘЛФИНАЗ. Казан

– Гореф-гадәтләребез буенча, электән үк бер йортка килен кайта икән, ул иренең әти-әнисенә «әти-әни» дип әйтә башлый. Кайда ничек, әмма барыбер әйтәләр. Дөрестән дә, әти-әни берәү була. Әмма хөрмәт, ихтирам йөзеннән, әйтергә кирәк. Аны әйтүнең кыенлыгы юк, ул начарлыкка илтми бит. Килен, әлбәттә, үзе сөйләшеп, башка бер фикергә килергә мөмкин. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисендә исә катгый рәвештә «әйтергә кирәк» дигән күрсәтмә юк.

Июнь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Чәрш	01:07	03:07	17:24	20:16	21:46
2	Пәнҗ	01:06	03:06	17:24	20:17	21:47
3	Җом	01:05	03:05	17:25	20:19	21:49
4	Шим	01:04	03:04	17:26	20:20	21:50
5	Якш	01:03	03:03	17:26	20:21	21:51
6	Дүш	01:02	03:02	17:27	20:22	21:52
7	Сиш	01:01	03:01	17:28	20:23	21:53
8	Чәрш	01:01	03:01	17:28	20:24	21:54
9	Пәнҗ	01:00	03:00	17:29	20:25	21:55
10	Җом	00:59	02:59	17:29	20:26	21:56
11	Шим	00:59	02:59	17:30	20:27	21:57
12	Якш	00:59	02:59	17:30	20:28	21:58
13	Дүш	00:58	02:58	17:31	20:28	21:58
14	Сиш	00:58	02:58	17:31	20:29	21:59
15	Чәрш	00:58	02:58	17:32	20:30	22:00
16	Пәнҗ	00:57	02:57	17:32	20:30	22:00
17	Җом	00:57	02:57	17:32	20:31	22:01
18	Шим	00:57	02:57	17:33	20:31	22:01
19	Якш	00:57	02:57	17:33	20:31	22:01
20	Дүш	00:57	02:57	17:33	20:32	22:02
21	Сиш	00:58	02:58	17:34	20:32	22:02
22	Чәрш	00:58	02:58	17:34	20:32	22:02
23	Пәнҗ	00:58	02:58	17:34	20:32	22:02
24	Җом	00:58	02:58	17:34	20:32	22:02
25	Шим	00:59	02:59	17:34	20:32	22:02
26	Якш	00:59	02:59	17:34	20:32	22:02
27	Дүш	01:00	03:00	17:34	20:32	22:02
28	Сиш	01:01	03:01	17:34	20:32	22:02
29	Чәрш	01:01	03:01	17:34	20:31	22:01
30	Пәнҗ	01:02	03:02	17:34	20:31	22:01

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Гыйбрәт ал!

«Атны нинди бәягә алдың?»

Бервакыт Җәрир исемле сәхабә, ат алырга дип, базарга үз хезмәтчесен җибәргән. Хезмәтче бер ат сатучыдан мал бәясен белешкән. Башта килешә алмасалар да, соңыннан ат бәясен 300 дирһәм дип билгеләгәннәр. Җәрирнең хезмәтчесендә бу кадәр акча булмаган һәм алар бергәләп Җәрир янына киткәннәр.

Җәрир хезмәтчесеннән: «Атны нинди бәягә алдың?» – дип сораган. Хезмәтче: «300 дирһәм», – дип әйткән. Башка бәяне ишетергә әзер булган Җәрир игътибар белән сатучының күзләренә караган һәм сорау биргән: «Син атыңны 500 дирһәмгә сатарга ризамы?»

Сатучы дәшмәгән, җавап бирмәгән. Ә Җәрир: «Бу ат өчен 600 дирһәм җитәрлек булырмы?» – дип сораган. Сатучы янә дәшмәгән, ә яңәшәдәге кешеләр моны гаҗәпләнеп күзәтеп торган. Җәрир бәяне арттырган: «Ә 700 дирһәм?»

Сатучы түзмәгән, гаҗәпләнеп: «Кем сез? Сатучымы әллә алучымы? Гомеремдә дә әйбернең үз бәясеннән артыграк бәһа тәкъдим итүчене күргәнем булмады. Әйтегезче, сез бу ат өчен ник шундый акча тәкъдим итәсез?» – дип сораган.

Ә Җәрир болай дип җавап кайтарган: «Расүлуллаһка бәйгать (ант) китергәндә, мин, һәр мөселман белән гадел һәм намуслы булачакмын, дип сүз бирдем. Ә синең атың 700 дирһәм тора. Аның өчен азрак түләсәм, пәйгамбәр галәйһиссәләмгә биргән антымны бозар идем бит».

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

МИЛӘҮШӘ ГАЗИЗУЛЛИНА:

«АПАНЫҢ УҢЫШЛАРЫ – МИНЕМ ӨЧЕН ЗУР ЭТӘРГЕЧ»

Бүген без «Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка икътисадчы, блогер, алып баручы һәм чәчәкләр үстерүче Миләүшә ГАЗИЗУЛЛИНАны чакырдык. Танылган җырчының сеңлесе булу – җаваплылыкмы? Мәдәни үзәктән читтәгеләргә игътибар һәм мөмкинлекләр җитәме? Петуния үстерү нәрсәсе белән кызыклы? Без шулар турында сөйләштек.

:: Ни хәл?

– Бик яхшы, рәхмәт! Ялымның соңгы атнасы. Шул форсаттан файдаланып, ирем белән теплицада петунияләр янында мәш килеп ятабыз әле менә.

:: Миләүшә, сез – блогер да, җырларыгыз да бар, чаралар да алып барасыз. Гадәттә, мондый «арсенал»ы булганнар үзәккә – Казанга ашкына. Сезнең Әлмәттән китәсегез килми кебек.

– Бу сорауны миңа бик күпләрнең биргәне бар. Казанда мөмкинлекләр күбрәк, диләр. Ләкин миңа Әлмәт ошый. Кечкенә ул, шундый рәхәт шәһәр. Төрле яктан үсү өчен мөмкинлекләр монда да җитәрлек. Киләчәктә ни буласын кистереп кенә әйтә алмыйм, тик бүген мин Әлмәттә. Минем монда гаиләм, төп эшем дә шушында (Миләүшә икътисадчы булып эшли. – **Ред.**)

:: Апагыз да (җырчы Гүзәлем), сез дә иҗатны үз итәсез. Бу – нәселдән килгән сыйфатмы?

:: «Соңгы кыңгырау» узды, чыгарылыш кичәләре җитә. Башкортстанда, әйтик, бәйрәм узган көннәрдә кибетләрдә хәмер сату тыелды. Моңа карата фикерегез ничек?

– Безнең чыгарылыш укучылары бик акыллы. Алар имтиханга әзерләнә. Әлбәттә, балаларны күз уңында тотарга кирәк. Әмма тегесе ярамый, монысы ярамый дип, гел саклап, кисәтеп торып та булмый. Алар үзләре аңларга тиеш.

КУКМАРА ФЕРМЕРЫ:
«200 ИПИДӘН БАШЛАДЫК»

«Куркырга кирәкми! Күңелеңдә мин булдырам дигән уй булырга тиеш. Артка карамаска, бары алга атларга. Туган җиреңне яратсаң, авылым бетмәсен, яшәсен дисәң, әллә кайлардан көч табыла».

Кукмара районының Аш-Бужи авылында яшәүче эшмәкәр, фермер Фәнис ХАМАТДИНОВ сүзләре бу. Башка җирдә читкә китеп эшләсәләр, монда, киресенчә, авылга киләләр. Уңыш сере нидә соң?

Фермерларның кадерле чагы

Фәнис Хаматдинов эшен җиде юнәлештә алып бара. «Кукмара сөте», «Адай икмәге» оешмалары җитәкли. Кибетләр тота, умарталыгы бар. Суган утыртып саталар. Чебиләр үстереп, тавык итеннән продукция ясый башламакчылар. Һәр эшендә ике улы ярдәм итә. Олы улы Илгиз җаваплылыгында кибетләр һәм пекарнялар булса, Фәнүсе сөт белән шөгыльләнә.

Без килгәндә, Фәнис абыйның зур эшләр белән йөргән чагы иде. Эшчеләр авыл башында күп еллар буш торган дуңгыз фермасын чебиләр тоту өчен җайлап яталар. Фермага кыйммәтле җиһазлар кайтарылган. Бөтен нәрсә автоматлаштырылган булачак икән. Инде компьютер артында утырачак белгечне укытып та кайтарганнар.

– Чеби үстерү – үзем өчен дә яңа эш. Район башлыгы фермалар буш ятмасын инде дигәч, тотынган идем. Ул чакта ферманың «ф» хәрефе дә юк, җимерелеп беткән иде. Дәүләт ярдәм итәм дип торганда, Аллага тапшырып, тәвәккәлләдек. Санкцияләр кертелгәч, безнең кебек фермерларга эшне алып бару җиңеләйде. Йөз белән борылдылар дип әйтимме соң шунда. Кыскасы, безнең кадерле чак. Шуңа күрә булдыра алганны эшләргә кирәк. Элек тиз генә кредит та ала алмый идек. Хәзер ул эш тиз башкарыла. Безгә 5 процент белән кредит бирәләр. Әнә шуның белән эшне көйләп була да инде, – ди Фәнис Хаматдинов. – Бу ферманы төзегәндә район ярдәм итте. 3 ферма түбәсен ябарга 1 миллион 200әр мең сум акча бирелде. Калганын үзебез башкарып чыктык. Шушы көннәрдә эшләтеп тә җибәрергә дип торабыз.

«Түләмәсәң, эшләүче юк»

Без әкренләп алга таба атлыйбыз. Фәнис абый үзенең яшьлек елларын искә төшереп ала. 1985 елда ул Киров өлкәсендә укып бетереп, үз авылына агроном булып эшкә кайткан. Яшь егеткә агроном эше белән бергә, профсоюзныкын да алып барырга туры килә. Аннары аны Сәрдекбаш авылына колхоз рәисе итеп куялар. Шул чорда үз эшен ачу теләге туа да инде. Эштән китә дә, күрше авылдагы иске пекарняны алып, эшли башлый.

– Эшне бер кечкенә урында башладык. Көненә 200 ипи пешерә идек. Ул чактагы авыр хезмәтне хәзер уйлыйм да шаккатам. Капчык-капчык оннарны хатыннар да күтәрә иде. Хәзер инде бөтенләй башкача. Ипине дә 10 тоннадан артык пешерәбез. Әле аның янында 28 төрле кондитер эшләнмәсе бар. Көненә күпме пешергәнебезне төгәл генә әйтеп булмый, – ди эшмәкәр. – Ипи ризыкларын яраталар. Аларны 11 районда 600 кибеткә таратабыз. Иртәнге дүрттә үк 19 машина ипи төяп чыгып китә. Татарстан гына түгел, күрше Киров өлкәсе, Мари Иленә дә алып барып бирәбез.

Сөйләшә-сөйләшә пекарняга килеп кергәнне абайламыйча да калдык. Анда эшнең кызган чагы иде. Бар җирдә тәртип. Фәнис абый иң элек тәмле икмәкнең ничек пешерелгәнен күрсәтә. Оннны чит илдән кайтаралар икән. Хәзер инде бер кило да он күтәрүче юк. Барысы да автоматлаштырылган. Камыр, әзер булгач, пешерүче кызлар алдына «килеп баса». Пекарняда барлыгы 105 кеше эшли икән. 38 мең сумнан 86 меңгә кадәр хезмәт хакы алучылар бар. Сабантуй бәйрәмендә, әйтик, узган ел 500 мең сумлык бүләк таратылган. Ә ел дәвамында иганәчелек эшләренә 1,5 миллион сум акча тотылган.

Автор фотосы

– Акча җәл түгел, авылыбыз гына яшәсен. Эшләп торганда акча була ул, – ди Фәнис Хаматдинов. – Мәчетләребездә азан тавышы тынмасын, бакчаларга балалар йөрсен, мәктәпләр эшләсен. Бар теләгем – авылны яшәтү. Бездә бит эшсез кеше юк хәзер. Кеше җитмәсә, читтән килеп эшлиләр. Андыйлар өчен кунакханә салдырып куйдык.

Әкренләп сөт комбинатына килеп җиткәнбез. Биредә каймак, сөт өсте, кефир, ряженка, катык, эремчек, сөт, май ясыйлар. Әкренләп сыргa да тотынмакчылар. Планнары зурдан. Авылда маллар гына бетмәсен. Фәнис абый, бетмәс, дигән теләктә. Ник дигәндә, халык сөт сатып, акча эшли икән. Кешеләрне сыерлы итүнең дә җаен тапканнар, тапшырасы сөтләре урынына акчаны алдан биреп куялар икән.

– Халыктан һәм фермерлардан 17 тонна сөт җыябыз. Аны бик тикшереп алабыз. Бары тик сыйфатлы гына сөт булсын, дибез. Санкцияләр кертелгәч, сөт пакетлары, шешәләрнең бәясе артты. Аны бермә-бер күтәреп куйдылар. Элек 1 сум 50 тиен торган пакет хәзер 5 сумга менде. Нишлисең, бизнеста йә туңасың, йә уңасың инде ул. Алтын урталыкны табып эшләргә кирәк, – ди ул.

Тыл кирәк

Фәнис абый безгә умарталыгын да, әти-әнисе йортын да күрсәтте. Ул тирәдән узганда, әти-әниле булуына да сөенүен яшермәде. Улы Илгиз йортына да алып барды.

– Шәһәрдә яшисе иде ул. Өйләнешеп, ике ел Казанда тордылар да, улым, кайтам, диде. Йорт салырга булыштык та, калганын үзләре булдыра хәзер. Киленебез дә үзебезгә охшап килде. Тормышның кадерен, яшәүнең ямен тоеп яшиләр, – ди әти кеше. – Балаларга нинди тәрбия бирдегез дисеңме? Тәрбия – үрнәк. Әти эчмәде, тартмады. Мин дә, малайлар да шулай.

Авыллары матур, йортлар төзек. Бакча-бакча суган үстерәләр. Анысы да – бер кәсеп. Фәнис Хаматдиновның да суган җире күп. Узган ел уңыш бик сөендермәсә дә, быел бер авылдашлары орлыклык суган сатып, 30 миллион сумнан артык акча эшләп алган. Бу мисалны Фәнис абый, йоклап ятмасаң, акчаң була, дип китерде.

Акча үз урынында кирәк булса, җан тынычлыгы да мөһим бит әле. Фәнис абый бу урында хатынына рәхмәтле булуын яшермәде. «Укытучы булып эшләде ул. Тиешле стаж җыеп, пенсиягә чыккач, эшләмә, дидем. Баштa бухгалтер эшләрен алып барды. Аннары бакча эшенә чумды. Минем аны борчыйсым килми. Эштәге вак-төяк күңелсезлекләрне аңа сиздереп тә тормыйм. Яратып өйләндем, яратып яшим, – ди. – Авылда үз эшен башларга теләүчеләргә киңәшем шул: тәвәккәлләгез. Мин уйлаугa, шундук эшләдем дә. Шөкер, бер дә үкенгәнем булмады. Үз-үзеңә ышаныч кирәк. Арттан этүче булмаса да, арттан килүче уларым бар. Оныклар үсеп килә. Һәр иртә кешеләрдән рәхмәт ишетәм. Әнә шул сүзләр яшәтә дә инде мине!»

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сыерлар да... җылы көтә

Башка елларны май уртасында көтү чыкмаса, авыл кешесе борчыла башлый иде. Быел шушы атнага кадәр «көтү» дип авыз ачкан кеше дә булмады.

Авылда һәр нәрсә табигать шартларына бәйле шул. Хәтта гади генә булып тоелган көтү чыгу вакыты да, быелгы кебек соңлаган язларга карап, ирексездән үзгәрә. Чыгудан мәгънә юк, үлән аз булса да күтәрелсен инде дип тә, мал күп, көтүлек әйбәт, болын кипсен дип тә, яр буйлары, үзәнлекләр бик юеш, сыерлар батып кала күрмәсен дип тә сабыр итүләре. Элегрәк сарык көтүе апрель азакларында – май башларында чыга да, аннан соң берничә көн үтүгә, сыерлар да көтүлеккә юл ала иде. Инде авылларда сарык көтүе беткәнгә шактый, быел исә шушы көн җитеп тә, безнең якларда әле нибары бер-ике авылда гына көтү чыккан килеш.

Чынлыкта көтү чыгу – кайсы чорда да авыл кешесе өчен тормыш ритмын үзгәртә торган зур вакыйга. Дүрт күзләп, санап көтә торган вакыйга. Көтәрсең дә, күздән туплаган ашлыкпечән запасы кимеп бара, быел ашлыгын да, печәнен дә табу җиңелләрдән түгел. Күздән дә авырдан туплаучылар булды, өстәвенә бер айга якын артыграк ашатырга да туры килде. Авылдагылар өчен иң рәхәт көннәрнең берсе ул. Сыер белән бергә кырга бөтен эш чыгып киткән кебек була! Малкайлар да сөенә. Җитәкләп, капкадан чыгуга, кемнеке сырт күтәреп чаба, кемнеке хуҗасын өстерәп алып китә, кемнеке иркенгә чыгу шатлыгыннан тояклары белән җир казырга керешә, кемнеке...

60 хуҗалыклы авылыбызда берничә йорттан кала һәркайсында берәр сыер асраган еллар да, соңрак бер өлеше сыерын бетергәндә, икенчеләре арттырып, икешәрне асраган еллары да күрдек. Җәйгә берничә генә көткән чаклар да, ай тулар-тулмаста килеп җиткән чаклар да булды. Менә сөткә бәяләр арткач, икешәрне-өчәрне асраучылар да артты, сыерлар саны да ишәйде...

Бездә шулай гадәтләнгән: күп урыннарда һәр хуҗалык үз сыеры санынча, көтүгә үзе чыга. Көтүче яллаган урыннар да бетә барадыр, ни дисәң дә, «электр көтүче»ләр бик тиз таралды, безнең районда аннан файдаланмаган авыл калдымы икән? Ә бит моннан берничә ел элек кенә, көтүче тапмаганга, сыерлары өйдә торган авыллар да булды. Алар да бу проблемадан шулай котылды.

Көтү димәктән, хәзер хуҗалары кебек үк, малкайлар да бик көйсезләнде, гадәтсезләнде. Кычкырганны да, куганны да белми, кая барганын, нинди печән кирәген аңламаганнары буа буарлык. Андыйлар иртәдән кичкә кадәр бертуктамый йөреп, башкаларны котыртып тора. Араларында көтүгә керә алмый, кушыла алмый тилмергәннәре дә була. Болар – «бабайлык» корбаннары. Карт сыерлар яшь малларга көтүгә ияләшергә ирек бирми. Бер яктан көтүче куалый, камчылый, ә икенче яктан, сыерлар үзләре сөзеп, читкә куып чыгара. Йә, ничек иялә̆шсен инде ул көтүгә?! Абзарда яшь бозаулары калган сыерлар өчен дә зур сынау бу көтү дигәнең. Кичкә таба аларның түземлеге бетә: көтү алдында, кайтыр сәгатен көтеп, «бии» башлый, көтүлектәге «капка»ны ачуга, кушаяклап чаба алар.

...Шунысы да хак: иртә җәйдән кара көзгә кадәр авыл көтү режимы белән яши. Барлык эшләр көтү чыкканчыга һәм кайтканчыга кадәр дип бүленә. Көтү сакларга дигән сылтау белән алдарак чыгып, күрше-күлән белән гәпләшә, һич югы аягын сузып, тын ала ул. Көтү кайтып, сыер савып, сөтеңне урнаштырганнан соң инде кич җиткәнен чамалый башлыйсың. Әле көтү чираты да синдә булып, имин генә үтсә... Бу көнне синнән дә бәхетле кеше булмый...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Гөлгенә
ШИҺАПОВА

БАШКА ХӘСРӘТ КИЛМӘСЕН

Теләчедә яшәүче Роза апа Ногманова белән бер дә уйламаганда таныштык. Шушы көннәрдә интернетта ниндидер җанвар 80гә якын чебине буып ташлаган, дигән хәбәр таралды. Әрәм булган кошларның хуҗасын эзләп таптык. Сөйләшә башлагач, Роза апаның күңел капчыгы тишелде...

Моннан 10 ел элек газиз баласын, ике ел элек ирен югалта ул. Шуңа да тормыштагы күңелсезлекләрне җиңелрәк кабул итәргә өйрәнгән.

– Чебиләремне югалткач, икенче көнне үк яңаларны алдым. Малны кире алып була аны... Киткән кешеләрне генә кайтару мөмкин түгел. Башка хәсрәт килмәсен, балаларым, оныкларым исән булсын, – ди ул, күңел яраларын кузгатып. – Ирем белән матур яшәдек. Гаиләкорганда миңа – 20, иремә 21 генә яшь иде. Югары уку йортын тәмамлап кайткач, аны төрле җирләрдә эшләттеләр. Ул кайда, без шунда идек. Шулай 10 ел йөрдек тә Теләчегә кайтып төпләндек. Өч улыбыз туды. Тик берсенең гомере кыска булды. Күңелнең төрле чагы бар. Кычкырып елыйсы килгән вакытлар да була, әмма түзәм. Мин елаудан ни файда соң?

Роза апаның олы улы Артур, Казанда укып кайтып, Арчада эшли башлый. Бервакыт Балык Бистәсе районына барырга туры килә аңа. Чалт аяз, кояшлы матур көн була. Артур юлда фаҗигагә юлыга, урында ук һәлак була. Ул чакта аңа – 32, хатыны Әлфиягә 27 яшь була.

– Беренче малайларына – 3 яшь, икенчесенә 3 кенә ай иде. Әлфия киленемә шалтыратып, улымның үлгәнен әйткәннәр. Сентябрьнең 21е иде. Ул чакларны искә алсам, күңелем тула. Никадәр уйламаска тырышсам да, газиз балам йөрәгем түрендә яши. Бик юксынам үзен. Әле ярый киленем белән оныклар яшәр көч бирә. Алар белән аралашып, тату-матур яшибез. Сабыйлар әкренләп үсә. Әлфиям дә башка кияүгә чыкмады. Кода-кодагыйларга да рәхмәт. Әтиләре булмаса да, сабыйларга ятимлекне онытырырга тырышабыз, – ди Роза апа.

Роза апаның икенче улы Айдар, өйләнеп, Теләчедә яши. Хатыны белән ике кыз үстерәләр икән. Кечесе Булат хатыны белән төп йортта яшәгән, йорт салып башка чыгуларына өч кенә атна икән әле. Алар өч бала сөя.

– Ирем Марат исән булса, бер дә кыен булмас иде. Коронавирус алып китте аны. 60 яшен тутырган гына иде, – ди Роза апа. – 2020 елның 12 сентябре иде. Башта салкын гына тигәндер дидек. Гадәттәгечә йөткерде, тән температурасы күтәрелде. Үзар диган идек. Мин үзем дә авырдым. Өйгә килеп дәваладылар. Әмә Марат абыеңны коткара алмадык. Хәле начарланды. Башта коронавирус диделәр, аннары инсульт булды. Бик тә терелеп кайтыр дип көткән идем... Балаларым үзләре белән бергә торырга да чакырган иде. Төп йортымны ташлап китәсе килми. Күпме гомер үткән, шушы йортта балаларым үскән... Шөкер, улларым ташламый. Бер көн дә ялгыз торганым юк. Алар – миңа, мин аларга йөрим. Киленнәрем кызларым булды, «әни» дип өзелеп торалар. Ә олы кешегә ни кирәк соң? Уларымның тормышына сөенеп, оныкларга шатланып, бар хәсрәтне эчкә йотам. Әнә чебиләр алып җибәрдем. Юкка күңелне төшермим әле. Тормышым бик матур. Балаларга терәк һәм кирәк булып яшәргә дә яшәргә әле.

Язманы әзерләп бетергән вакытка килене Айсинәдән әнисе турында җылы сүзләр килеп ирешә: «Безнең әни кебек сабыр кеше юк инде ул. Аллаһы Тәгалә ничек кенә сынаса да, түзә. Төп йортта җиде ел бергә яшәдек. Әнинең җылысын тойдым, кадерле булдым. Без аңа сәламәтлек, гомер сорыйбыз, ул безгә бик кирәк».

«ӘНИ» ДИЯРГӘ ТИЛМЕРМӘСЕННӘР...

Үзе «әни» дип әйтә алмагач, ятимнәрне сөендерергә уйлаган ул. Кечкенәдән бер теләге була: күп итеп бала тәрбияләргә хыяллана. Ятимнәрне дә әниле итәргә, инвалид бала алып үстерергә тели. Актаныш районының Киров авылында яшәүче Венера Сабитова ун ятим бала тәрбияли.

– Үзем ятим үстем. Шуңа балалар алырга булдым да инде. Әти белән әнием эчтеләр. Без туганнарга кунакка киткәч, әти әнигә суккан, ул үлгән. Энем белән мине – әтинең бер абыйсы, кече энемне икенче абыйсы үз гаиләсенә сыендырды. Әтине төрмәгә утырттылар. Ул, кайткач, яңадан өйләнде. Яңа әни начар булмады... Берсе дә исән түгел инде, сүзләрем дога булсын, – ди ул.

Ире Алмас белән алар күршеләр була. Алмасның әнисе кулын имгәткәч, Венерага сыерларын саварга туры килә. «Киленем итәм әле мин сине», – дип озатып кала булачак каенана. Бу сүзләр фәрештәнең «амин» дигәненә туры килә.

– Озак та үтми, кереп, әтидән кулымны сорадылар. Ризалашканымны сизми дә калдым. 17 яшем тулган гына иде әле. Шөкер, үкенмәдем, матур яшибез. Яшь вакытта үпкәләгән чаклар да булды инде. Олы улымны көткәндә, иремә ачуым чыгып, Оренбургка китеп бардым. Шул китүем гомерлек сабак булды, – дип искә ала Венера апа.

Ире белән ачуланышкач, ул юлга чыга. Әле бәби табарга бер ае булса да, поездга утыруга, тулгагы башлана.

– Хәрби киемдәге өч ир бәбиләтте мине. Бала 2 кило да 200 граммлы булып туды. Бер атнадан апалар мине килеп алды. Ирем, дүрт ай үткәч, яныма килде. Шуннан бирле үпкәләшеп утырган юк, – ди ул.

Поездда туган малай – Рузатның гомере генә кыска була. Моннан ун ел элек дөньядан үз теләге белән китеп бара ул. Шушы хәсрәттән соң әнисе исемен алыштыра. Аны хәзер Мәрьям дип тә йөртәләр.

– Ашыгып яшәде шул ул балам. Армиягә киткәнче, кояш кебек елмаеп кына торган бала иде ул. Тик боегып кайтты. Бер ел кая барып бәрелергә белмәде. Өйләнде, кызы туды. Яшисе дә яшисе иде бит югыйсә. Нииләр булгандыр инде баламга... Киленем Алсуның әниләренә кунакка кайтып киткән көне була. Улым, миңа шалтыратып: «Әни, бәхил бул, мин китәм», – диде. Аяк астымда җир убылдымыни! Имәндәй баламны җир куенына салдык. Шөкер, киленем белән аралашып яшибез. Оныгыма 11 яшь тулды инде...

Рузаттан соң туган кызы Алсу Актанышта яши. Ире белән дүртенче улларын көтәләр икән. Кече улы Азат Казанда эшли. Рузатны югалтканчы ук, ятим балаларны тәрбиягә ала Сабитовлар гаиләсе. Ә аннары ачы хәсрәтне шушы сабыйлар оныттыра.

– Иң элек бертуган Руслан белән Алинәне уллыкка алдык, үз фамилиябезне бирдек. Бала алу вирус төсле ул. Бер алгач, гел аласы килеп тора. Ирем белән уйлаштык та 10 айлык Лилияне алдык. Шул вакытта күрше хатыны үлеп китте. Аның беренче никахтан туган кызы бар иде. Ире үз балаларын алды, бу кызны калдырды. Йөрәгем янды бит шуңа. Ничек итсәм иттем, Лиананы үзебезгә алдым. Шөкер, күршедәге туганнары белән уйнап үсте. Әнисе Вәсилә риза булып

ятадыр. Безгә килгәндә, Лианага 13 яшь иде. Мин бит әнисез калганда үзем дә шушы яшьтә идем, – ди Мәрьям апа.

Лианага хәзер 24 яшь икән. Кыз югары белем алган, эшкә урнашкан. Әти-әнисе машина да алып биргән.

Бүген Сабитовларда 9 бала яши. Руслан белән Алинә янына тагын өч бертуган Сибгатуллиннар һәм Бутаковлар килеп кушылган.

– Мин беркайчан да сабыйларга үз әниләрен начар итеп күрсәтмим. Социаль челтәрләр аша аларны эзләп табып, үзем язам әле. Бер гаиләнең әнисе килгәләп йөрде дә югалды. Икенчесенеке аралашуны кирәк дип тапмады. Иң кызганычы шул: бала ананы гомер буе йөрәгендә йөртә, ана тиз оныта, – ди Мәрьям апа.

Ул балаларын эшкә өйрәтеп үстерә. Шуңа да гел кечкенә сабыйларны алырга тырышкан. Сабый чакта гаиләгә килеп кергән баланы тәрбияләү җиңелрәк, ди. Баланың геннары холкы өчен җавап бирә. Ә менә тәрбия үстергән кешедән тора дигән фикердә күпбалалы әни. Авылдашлары: «Балаларыгыз нәкъ үзегез инде, сезнең кебек сөйләшәләр», – дип әйтә икән.

– Без күңелле яшибез. Балалар белән төрле чаралар уздырабыз. Кеше булып үссеннәр, дим. Авылда ялгыз яшәүче өлкәннәрнең хәлләрен беләбез. Ай саен берәр бәйрәм уңаеннан бишәр бүләк таратабыз. Язын кырда эшләүчеләр янына чыгабыз. Чишмәләр җыештырабыз. Зиратка өмәгә йөрибез. Шушы эшләр белән балаларымны тормышка өйрәтәм, – ди Мәрьям апа. – Сабыйларым дин юлына басты. Үзләре белеп намаз укыйлар. Быел уразада бер генә көн дә калдырмыйча тәравихка йөрделәр. Аларга карап, күңел сөенә. Димәк, сабыйларым – дөрес юлда.

Мәрьям апа ятимнәрне үз канаты астына алгач, бар авыруын оныткан. Корвалол да эчкәнем юк, ди. Ә бит мәшәкате дә шактый. Сабыйларны аякка бастыру – бер хәл, аларның туры юлдан китүен дә тели. Беркайчан да юкка-барга борчылмыйм, ди үзе. Сабыр итәргә дә өйрәнгән. Аллаһы Тәгаләдән узып булмас дип, шөкер итә.

– Гомерем буе «әнием» диярга тилмердем. Мәктәптә укыганда, башкалар әниләренә эндәшкәндә, мин читкәрәк китеп, «әнием-әнием» дип пышылдап кабатлар идем. Ә төннәрен юрган астында гел «әнием» дип кабатлап яттым. Шушы сүзне ишетү дә шундый рәхәт миңа, – ди ул. – Үзем әйтә алмасам да, миңа күпме сабый шулай дип эндәшә. Иң зур бәхет менә шул. Калганы була аның. Күңелгә рәхәт, җанында тынычлык икән, рәхәтләнеп яшисең.

ЧУЛПАН ЗАКИРОВА:

«ЯХШЫ БИЮ МЕҢГӘ БЕР БУЛА»

Татар халкы өчен бию – нәрсә? Хәрәкәтләрдә милләтеңнең үткәнен, шатлыгын, фаҗигасен сурәтләп буламы? Мәрҗәнгә тиң биюләр ничек туа? 25 еллык тарихы булган «Казан» бию ансамбле җитәкчесе Чулпан ЗАКИРОВА белән әнә шул хакта сөйләштек.

:: «Казан» бию ансамбле оешуга – 25 ел. Бу елларга, ансамбльнең иҗат дәверенә бүген нинди бәя бирәсез?

– Ансамбль 25 ел дәвамында гел үсештә, хәрәкәттә булды. Минем өчен иң мөһиме шул. Нинидер эшкә алынганда, мине һәрвакыт бер сорау борчый: дөрес юнәлештә, дөрес юл белән барамы? Инде хәзер, 25 ел узгач, артка борылып карыйм да, ансамбль дәрәҗәле чараларга чакырыла, югары бәяләнә икән, димәк, ялгышмаганмын, дип уйлыйм. Димәк, без сәнгатькә дөрес мөрәҗәгать иткәнбез, дөрес юнәлешне сайлап алганбыз.

:: Чирек гасыр дәвамында бер миссиягә хезмәт итү, дәрәҗәне төшермичә, һәрвакыт яңалыклар белән шаккатыру – зур җаваплылык.

– Моның өчен бертуктаусыз эзләнүдә булырга кирәк. Торгынлык – җәмгыять үсешенең иң явыз дошманы ул. Бүген без тамашачыга бер программа тәкъдим итсәк, мин башымда тагын өч-дүрт яңа проект йөртәм.

Идея-фикерләр башыңа үзеннән-үзе килеп керми, билгеле. Нинди дә булса этәргеч кирәк. Ә мине бик кечкенә бер нәрсә дә илһамландыра ала. Нинидер картина күрдемме, китап атамасына күзем төштеме, берәр матур төс чалыны киттеме – табигатьтәге, тормыштагы санап бетергесез детальләр... Дөньядан артта калмау, иҗаттагы яңалыклардан һәрдаим хәбәрдар булу шулай ук мөһим. Мин даими рәвештә Мәскәү, Санкт-Петербург кебек зур шәһәрләргә барып, спектакльләр карыйм, эзләнәм.

Безнең биюләрнең дә, костюмнарның да кабатланмас булуы – көчле командаиның тырышлыгы нәтиҗәсе. Һәр биюне өчәр, дүртәр, кайчак бишәр кеше бергә әзерли. Юнәлешне билгеләүче мин булсам да, һәр биюне без күмәкләшеп, киңәшләшеп куябыз. Безнең командада искиткеч көчле, талантлы балетмейстерлар – Илдар Хәмидуллин һәм Фәнис Исмәгыйлов эшли. Күп кенә биюләребезне шушы ике кеше иҗат итеп, сәхнәгә чыгарды.

:: Сез тарихка еш мөрәҗәгать итәсез. Бу шулай ук эзләнүне, фактик яктан төгәллекне таләп итә. Хәрәкәтләр генә түгел, костюмнар, биюләрнең атамалары яхшылап уйланылган булырга тиеш...

– Тарихка мөрәҗәгать иткәндә, төрле чыганакларны барлыйм. Әдәби, публицистик язмалар белән танышам, бу өлкәдә хезмәт куючы белгечләр белән сөйләшәм, төрле кешеләр, төрле фикерләр тыңлыйм. Әлбәттә, бу – бик зур эзләнү. Биюне, музыка куйдың да хәрәкәтләнә башладың, дигәнрәк формада күз алдына китерүчеләр, зинһар, болай уйлап ялгышмасыннар иде. Бию – аналитикага корылган зур эш, иҗат ул. Аңа төрле яклап килергә, идеядән алып, вак кына детальләренә кадәр уйларга кирәк. Шуңа күрә көн дә яңа бию куелмый. Шәп, кызыклы биюләр энҗе-мәрҗәнгә тиң. Үлмәс, мәңгелек җырлар тарихта берничә генә бит. Алар телдән-телгә, буыннан-буынга күчә, онытылмый. Яхшы биюләр дә шулай мәңгә бер була.

:: Фольклор композицияләр еш кына тәнкыйтькә дучар була. Программа гына түгел, костюмнар да тәнкыйтьләнә. Сезгә бу күренеш белән очрашырга туры киләме?

– Әлбәттә. Тик тормасаң, нидер эшләсәң һәм синең ул эшең башкалардан аерылып торса, беренчеләрдән булып тәнкыйть «килеп төшә». Фикерләр җирдәге кешеләрнең санына тигез, диләр бит. Кемдер безнең сәнгатьне ярата, кемдер биюләрне бөтенләй аңламый һәм яратмый. Кайберәүләр яңалыкларны кабул итми. Ә мин һәрвакыт үсү-үзгәрү ягында. Дөньябыз үзгәрә бит. Бүген халыкның фикерләве, технологияләр, яшәү рәвеше башка. Спортчылар яңадан-яңа рекордлар куя. Шулай булгач, без дә үзгәрергә тиеш. Бүгенге биюләр белән моннан, әйтик, йөз ел элеккеге биюләрне чагыштырсаң, исең-акылың китәрлек. Хәрәкәтләр катлаулана, биючеләрнең яңа мөмкинлекләре ачыла.

Мин тәнкыйтькә шатланам гына. Дәрт, көч өстәгәндәй итә ул. Кызурак кеше булгач, сүгеп ташлыйлар икән, бик тиз кабынып китәм. Һәм казына, уйлана башлыйм. Билгеле, бу һәр кешенең фикерен кабул итәм дигән сүз түгел. Моннан бары тик билгеле бер нәтиҗә чыгарып, тагын да яхшырак эшләргә генә кирәк.

> Сине тәнкыйтьлиләр икән, димәк, синең хезмәтең башкаларның хисләрен уяткан, күңел кылларын тибрәткән. Моңа сөенергә кирәк. Тәнкыйть – битарафлыкка караганда күпкә яхшырак нәрсә ул.

:: Ансамбльдә егетләр дә бар. Хатын-кыз булярак, алар белән җитәкчелек итү авырмы?

– Әлбәттә, авыр. Табигате буенча, ир-ат, хатын-кыз белән чагыштырганда, көйсезрәк була. Хатын-кызга бер әйтү җитә – тора да чаба. Ә ирләрнең көен көйләргә, сыйпап торырга кирәк. Билгеле, һәрвакыт аларның җаенда торып булмый, аңа вакыт та җитми. Әйткәләшкән чаклар да була. Ләкин безнең коллективта 20дән артык ир-ат бар икән, димәк, мондагы рухи мохит инде җайланган. Гел бергә булгач, мөнәсәбәтләребез якын туганнарныкына охшап бетте.

:: Сез – сәхнәгә егетләрнең гаярьлеген күтәргән кеше. Моңарчы алар сәхнәгә корал тотып чыкмый иде кебек.

– Моңа мине атаклы драматургыбыз Туфан абый Миңнуллин рухландырды. Нииндидер бер спектакль премьерасыннан соң очрашкач, ул: «Биюләрегезне карап барам, матур гына эшлисез. Зинһар, чын ир-егетләр биюе уйлап тап әле син. Алайса, безнең егетләрне кырда йөрүче көтүче яки чабатачы кебек кенә күрсәтәләр. Ә бит безнең Болгар дәүләтендә нинди көчле гаскәребез булган! Безнең ирләребезнең көчен сәхнәдән дәрәҗәле, чын һәм матур итеп күрсәт әле», – диде. Шуннан соң уйлана башладым. Шушы уйлар һәрби биюгә әйләнде һәм сәхнәгә менде. Махсус әлеге бию өчен Казан авиация заводына барып, кылычлар һәм калканнар ясаттык. Әйтәм бит, идея һәм максаты гына булсын. Башланган эш – беткән эш, ди бит безнең халык.

:: «Казан» ансамбленең күпләр кызыгырлык үзәге бар. Ләкин ул мәдәни үзәктән читтәрәк. Бу мәсьәләне ничегрәк җайлыйсыз? Тамашачыны нинди ысуллар белән җәлеп итәсез?

– Шушы еллардагы иҗат дәверендә «Казан» бию ансамбленең үз тамашачысы тупланды дип әйтә алам. Алар безне белә, ярата һәм яңа программаларыбызны көтеп ала. Шуңа күрә тамашачыбызны яңа үзәккә китерү артык авыр булмады. Билгеле, яңа җиргә беренче көннән үк кеше килеп тулмый. Моның өчен эшләргә, тамашачы өчен кызык булырдай тамашалар тәкъдим итәргә, тамашачыны өйрәтергә кирәк. Без бу җәһәттән шактый актив эшлибез. «Казан» ансамбле шәһәр филармониясе составында эшләгәч, җырчылар һәм оркестрлар белән күмәк музыкаль спектакльләр куя башладык. Бу өлкәдә тиешле дәрәҗәдә эшләсәң, авырлыклар булыр дип уйламыйм.

– Сез – үзләрен сәнгатькә багышлаган гаилә вәкиле. Моның киләчәгегезгә йогынтысы булмый калмагандыр.

– Әйе, бу турыда белмәүчеләр юктыр инде: әтием дә, әнием дә – татар халкы өчен зур хезмәт куйган кешеләр. Һәм минем иң зур киңәшчеләрем. Нинди генә проектка алынсам да, иң беренче булып аларга сөйлим, алар белән киңәшләшәм. Инде хәзер үзем дә шактый тәҗрибә тупладым, командам да бар. Ләкин барыбер алар белән сөйләшмичә эшкә тотынмыйм. Әнинең театраль яктан, әтинең оештыру өлкәсендәге тирән, күп яклы белемнәре – миңа терәк-таяныч. Шуңа күрә әти белән әнием – минем өчен беренче урында.

:: Сезнең өчен бию – нәрсә ул?

– Кеше күңеленә хуш килгән эшне гомере буе да тапмаска мөмкин. Үзеңне тулысынча ача торган өлкәне тапкансыз икән, бу – үзе зур бәхет. Мин үземне хәтерли башлаганнан бирле сәхнәдә. Могаен, минем өчен башка тормыш әзерләнмәгән булгандыр. «Син биючеме, артистмы?» – дип сораганда, мин үземне бии торган артист һәм уйный торган биюче дип атыйм. Театрда үскәч, драманы бик якын итәм. Ә бию – минем икенче ятым.

:: Гадәттә, бию ансамбльләренең сәнгать җитәкчеләре читтән күзәтә, ә сез бүген дә сәхнәдә биисез. Ничек формада ничек тотасыз үзегезне?

– Берничек тә түгел. Табигатьтән бирелгән зур бүләктер инде бу. Рәхәтләнеп төнлә утырып ашыйм, телəгәнемнән беркайчан да баш тартмыйм, үземне чикләмим, диеталар тотмыйм. Ә инде хәрәкәтләнүгә килгәндә, яшәү рәвешем шундый булгач, артык көч куясы да юк.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Блиц-сораштыру

– Яраткан хореографыгыз?

– Төгәл генә бер кешене атый алмыйм. Һәрберсенең кайсыдыр ягын үз итәм. Шулай да, Игорь Моисеев һәм аның ансамбленең иҗаты алдында баш иям, сокланам.

– Яраткан авторыгыз?

– Классиклардан – Эрих Мария Ремарк һәм Александр Куприн. Ә заманча авторлар арасыннан берсен генә аерып әйтә алмыйм.

– Мөмкинлек булса, тормышта нәрсәне үзгәртер идегез?

– Һава торышын. Казаннан китәсем килми, ләкин җылы һава торышы булган җирдә яшәр идем. Һәм, мөмкинлек булса, әти-әниемне мәңге яшәтер идем.

– Тормыш девизыгыз нинди?

– Кызыксын! Дөньябыз шулкадәр төрле, бөтенесен күреп, тотып карап бетерәсе килә.

– Иң зур хыялыгыз?

– Балаларымның тормышта үз урыннарын тапканын күрәсем килә. Күңелең кушкан, яраткан эшеңдә эшләү – кеше өчен иң мөһим нәрсәләрнең берсе. Рәхәтләнеп эшенә барса, йөгерә-йөгерә өенә кайтса, шул вакытта гына кеше дөньяга ачык була һәм яшәүдән тәм таба. Кызларымның шушы халәтен күрергә телим.

МАРАТ ӘМИРХАНОВ

ШӘҺРЕ БАНУ

< Дәвамы. Башы 12, 20 май саннарында

Тарихи белешмә:

Тарихчы галим Шиһабетдин Мәрҗани «Күпне белсәң – асарлар, юаш булсаң – басарлар» дигән әйтем шул йолага бәйле рәвештә туган булырга тиеш дип саный.

Шушы кыска гына вакыт эчендә дә Ибне Фазланга шактый гына сәер хәлләр белән күзгә-күз очрашырга туры килде. Үзләрен мөселман өммәтеннән дип санаган ир-атлар белән хатын-кызларның шәпшәрә килеш бергәләшеп су керүләрен күреп тә чөгендердәй кызарган иде. Дин әһеленең исе дә китмәде, бездә гомер-бакый шулай инде, дип кенә куйды.

– Бу соң зина кылуга туп-туры юл лабаса, – диде Ибне Фазлан.

– Андый хәлнең булганы юк, була да алмый, – диде мулла, – бу үзеңне үлемгә дучар итү икәнен һәркем белә. Йолабыз шундый: андыйларның гәүдәсе тураклана һәм дә агач ботагына элелә. Козгыннарга – азык.

Белеквар ислам диненә йөз тотып, бик дөрес эшли, дип уйлап куйган иде Ибне Фазлан, ошбу кыргыйлыктан адәм баласын бары шәригать кенә йолып ала ала.

Кызлар мәктәбе – Гыйрфан җәзирәсе, Мәгърифәт утравы.

Бу – Ибне Фазланның бәясе. Ошатты ул кызлар мәктәбен, бик ошатты. Җәй айларында дәресләр булмавы гына кызганыч. Гарәпләрдә, мисал өчен, мондый мәктәпләр юк. Гарәпләрдә кыз баланы әдәп-әхлакка, аш-су осталыгына, кул эшләренә, дөнья көтү серләренә ана кеше өйрәтә, төшендерә. Үзе ничек, кызы да шул калыпта тәгаенләнә. Наданнан – надан, өлгердән – өлгер, ялкаудан – ялкау... Ә бу мәктәптә талибәләргә белем-күнекмәләрне мөгаллимәләр бирә икән.

Яшь буынны тормышка яраклы итеп үстерү җәмгыятьнең дә тотрыклылыгы дигән сүз. Бу бик яхшы. Шуның белән бергә, яңа иман китергән яшь мөселмәләргә диннең асылын, аның кануннарын, шәригатьчә яшәү нечкәлекләрен аңлату да бик мөһим. Гомумән, мәдрәсәләр күбрәк ачылса, дин тотудагы төрлелек алда телгә алынган сәер гореф-гадәтләр дә күзгә күренеп кимер иде.

Бану бикә дә килеште бу фикер белә. Ләкин әйтте:

– Мәдрәсәләр ачар өчен, хөрмәтле сәркатип-илче, әзерлекле мөгаллимнәр кирәк, ә бездә алар юк дәрәҗәсендә. Мин үзем шәхсән кызлар мәктәбе өчен Багдад сәүдәгәре Муса әкәгә кияүгә чыккан Зөбәрҗәт яугирә булышлыгы белән генә ике мөгаллим китертә алдым. Бу җәһәттән дә без сезнең ярдәмгә бик мохтаҗбыз.

– Үтенечләрегез, һичшиксез, хәлифәбезгә җиткерелер.

Ибне Фазлан шактый күп кеше белән очрашып сөйләшергә өлгерде инде. Арада төрлесе бар. Аны исә кемсәнең җәмгыятьтә тоткан урыныннан битәр, фикер йөртү күәсе, күңелендәге логик эзлеклелектә җиткерә белү осталыгы, тел байлыгы кебек зыялылык сыйфатлары кызыксындыра. Ык-мык килүчедән, кая ул рисалә өчен мәгълүмат туплау, башыңа авырту гына аласың. Ә аңа мәгълүмат кирәк, күп кирәк.

Бану бикә аларның барысыннан да өстен иде. Бу дөньяда ярты гасырга якын яшәү дәверендә шактый гыйлем тупларга өлгергән, күп нәрсәдән хәбәрдар. Шул исәптән, илаһиун вә илаһият диңгезләрендә дә ярыйсы гына йөзә. Һәрхәлдә, үзенең әйтүенә караганда, Хәсәен бине Ибраһим дамелладан бик теләп белем эстәгән.

Ул әңгәмәдәшен төрле яктан сынамак итеп, хәтта ерак эра бакчасына да таш атып карады.

– Хатын-кыз идарәчеләрдән Клеопатра язмышы сезне ни дәрәҗәдә кызыксындыра? – дип сорады.

Бикә ирен читләре белән генә елмайгандай итте дә:

– Хөрмәтле сәркатип-илче, мин бит – яугирә, мине барыннан да элек сузылмалы шам кылыч, еракка очучы сәрпи ук ише орыш яраклары күбрәк кызыксындыра, – диде, – шулай да, Клеопатраның Мисыр патшабикәсе булуы ничектер колагыма кереп калган. Ә менә сезнең мәгълүматны рәхәтләнеп тыңларга әзермен.

Сәркатип-илче, хәл алгандай, күзләрен кыса төшеп, кулы белән һаваны ярып алды да:

– Мисырда Клеопатра исемле җиде патшабикә тәхеттә утыра, – диде. – Дан алганы – җиденчесе. Аның турында искиткеч чибәр, бик тә булдыклы, үз сүзен сүз итүче, чын гыйшык иясе дип тәкрарлыйлар. Данлыклы Рим императоры Юлий Цезарьны да үзенә караткан ул.

Клеопатра кебек үз язмышын гына түгел, мәмләкәт язмышын хәл итәр дәрәҗәдәге хатын-кыз идарәче булу өчен үз-үзеңнән дә яхшы булу шарттыр, мөгаен. Менә сез, «Кала тау», «Кызлар каласы» шәһәрчекләрен төзегәнсез, авыр булдымы?

Бану озак уйланып тормады, гадәтенчә көлемсерәп кенә:

– Беләсезме, Ходай кыз-хатын җәмәгатен шулай яраткан ки, аның калебендә бик күп затлар көн күрә: алиһә, җани мәгъшука, фәрештә, пәри, галимә, шәйтан, мөгаллимә, җитәкче... күп алар... Мәгънәсе исә бик гади, шуларның кайсын уяталар, хатын-кыз шул сыйфатта була.

– О-о, сез әле фәлсәфәче дә икән ич, бикә!

– Коръәни Кәрим шулай өйрәтә. Мин ән-Ниса – хатын-кызлар сүрәтендәге аятьне һәрвакыт күңелемдә йөртәм. Анда әйтелә: «Сез үзегезнең малларыгыз белән дә, үзегез белән дә сыналырсыз, сезгә кадәр китапка ия булганнардан һәм мөшрик булучылардан күп рәнҗеткеч сүз ишетерсез. Әгәр сабыр булсагыз һәм тәкъвә булсагыз, хакыйкатьтә, бу – эшләрдә нык булудан бит».

– Ир-ат – хакыйкатьтә, тискәре халык, аның үз утызы утыз. «Кызлар каласы»ндагы вазгыять аларга, мөгаен, бик ошап бетмидер, – дип сәркатип әңгәмәне җирле шартлар юнәлешенә борып җибәрде.

Бикә бу юлы, шуны да аңламыйсызмы әллә, дигәндәй, әңгәмәдәшенә җәлт кенә күз атып алды. Шуннан соң гына:

– Без бит ир-атларны алыштырмыйбыз, фәкать алар белән бер хокукта уртак мәшәкатьләр дулкынында кулга-кул тотынышып яшибез, эшлибез, яу чабабыз, – диде.

Ошбу җөмлә Ибне Фазланның колак очыннан гына шуып узды, күңелен кузгатмады. Чөнки йөрәген шушы керфек каккан арада гына булып алган йөгерек караш өттереп алган иде, башы әйләнеп китте.

Дөрес, кылган чәчле бу ханыманың күкрәк түреннән чыккан үтә дә ягымлы, үтә дә моңлы тавышы башта ук күңеленә хуш килгән иде. Була торган хәл. Ә бу өттергеч караш исә бөтен калебенә үтеп кереп, ниндидер ашкынулы хисләр уятты. Хәтта эч серләрен бүлешү теләге дә уянып китте. Югыйсә ул – йомакай бәндә, барысы да – яхшысы да, яманы да – үз эчендә, сыны катса да, сер бирергә ашыгучылардан түгел. Яшәү шигаре дә шуңа охшаш: «Аһ димә, дошманнар ух димәсен».

Ул бикәнең язмышыннан хәбәрдар иде инде. Канаты каерылган ятимә ханым. Үзе дә шундый язмышта. Яратып өйләнгән хатыны баладан вафат булды. Бу югалтуны авыр кичерде, бик пар килгәннәр иде. Бераздан яңа тормыш та корып карады каравын, тик уңыша алмадылар, аерылышырга туры килде.

Бану хатын-кызларга гына хас әчке сиземләү белән каршысында утырган илченең хәл-халәтен ул үз тоемлаганчы ук абайлап алган иде инде. Ялгызак ир-егетнең генә кыяфәте шундый сагышлы була, назга сусаган ир-егет кенә кыз-хатынга туры карарга базмый, керфекләрен түбән салып кына сөйләшә, гыйшкы уянган ир-егет кенә дулкынлануын сүз калыбына салып, яшерергә тырыша...

Һәм илченең бу халәте үзенә дә ошый иде. Кайдадыр еракта, бик еракта томанланып яткан хисләре таш-тауны ерып, җир өстенә ургылган кайнар чишмәдәй искәрмәстән генә бөтен асылын биләп алды. Бу инде күптән онытылган, шул ук вакытта бик тә таныш искиткеч ләззәтле хис иде. Әгәр шундый ук хис кичерүче илче гамәли хәрәкәт дулкынына керсә, ахыры ни белән беткән булыр иде – анысы билгесез, әмма ир-егетнең кыюлыгы җитмәде, утлы тойгы кабынмыйча сүнде.

Ул арада бикә дә үз халәтенә кайтырга өлгергән иде инде.

– Хөрмәтле сәркатип-илче, Суарга бару турында сүз кузгаткан идегез, борчылмагыз, сезне озатып куярлар, – дип, урыныннан торып басты. Ишек катына җиткәч, башын бормыйча гына өстәде:

– Игътибарыгыз өчен рәхмәт, очрашу да, әңгәмәләрегез дә бик файдалы булды.

– Бикә...

– Хушыгыз!

Алар башка күрешмәделәр. Бану йокысыз төннән соң иртән иртүк Кыз күленә юл тотты. Шатлыклы чакларында да, кайгылы чакларында да, күңеле җилкенеп, үз-үзенә урын таба алмаган ашкынулы чакларда да ул шушында килә, изге Айтулы кызга мөрәҗәгать итеп, юаныч таба, борчыган сорауларына җавап ала.

Әле дә көзгедәй ялтырап яткан күл өстендә җил шаярткан шадра дулкыннарга карап, эч серен чиште дә:

– Айтулы кыз, киңәшеңне бир, миңа нишләргә? – диде.

Кинәт кенә җил кузгалып алды, күл өстендә өермә купты. Һәм шул ярсу гарасат эченнән Айтулы кызның тавышы яңгырады:

– Хәтереңдәме, тәүге саф вә пакь мәхәббәт ләззәтен минем күлем буенда татып, шушы өермәдәй зилзиләле рәхәтлек кичергән идегез. Ярмәк углан минем эзем калган җирдән туфрак алып, сиңа да үптерде, үзе дә үпкән иде.

– Хәтеремдә, бик хәтеремдә...

– Хәзер каберенә барып, миңа сөйләгән сүзләрне аңа да сөйлә.

– Ул мине гафу итәрме?

– Ярмәк ише олуг җиһангир җәмәгатенең башка кеше куенына керүе хыянәттән бигрәк, җинаять булыр иде...

Билгеле, безгә инде мәгълүм, бу – Бануның үз күңелендә, үзе күрергә теләгән риваяти фаразлаулар гына. Әмма ул аларга ышана. Ә үзең ышанган хакыйкать – иң хак хакыйкать.

Ахыры бар >

Шигърият

Рәниф ШӘРИПОВ

ҮТӘ УЛ

Май аенда көзге җилләр исеп,
Җәй аенда карлар яуса да,
Аяз көнне күкләр күкрәсә дә,
Барысы да була, каушама.

Кыйбла җуеп, адашкалап йөргән,
Көтелмәгән җилләр иле бит.
Боз сугасын кем уйлаган аның,
Көннәр җылы, аяз иде бит.

Тернәкләнеп килә яшел үлән,
Күпме гөлне изеп боз суккан.
Юанмагыз, көннәр аяз, диеп,
Давыл килеп чыга бит юктан.

Аяз көндә кинәт күк күкрәсә,
Гөлбакчаңа боз-кар яуса да,
Барысы да үз көенә кайта,
Барысы да уза, каушама.

КАКЫ ЫЗАНЫ

Истән чыкмый һаман. Шигырь язам.
Тотып атам янә, сызам да.
Бәхет тулы гамьсез көннәр булган,
Какы үскән чакта ызанда.

Монда шомырт. Монда бәрәңгеләр.
Менә монда суган түтәле...
Барысы бар. Барысы да җитә.
Юк булгач, юк инде бүтәне.

Гафифәттәй белән уртак ызан,
Какы үскән чагы дөньяның.
Сихри мизгел, ләкин ул вакытта
Кем кадерен белгән соң аның?

Язган булам. Кемгә кирәк соң бу?
Тотып атам, сызып бозам да.
Шуны гына беләм: без барында
Какы үсә иде ызанда.

Шомырт корган, ызан сукаланган.
Тулып ята хәзер бүтәне.
Күз алдымда чәчәк тулы ызан,
Какы, шомырт, суган түтәле...

2021

БЕРДӘНБЕР МӘХӘББӘТ

Ак хыяллар, ак бәхетләр...
Акылдан яздым инде.
Ак күңелгә кара белән
Язмышымы яздым инде.

Эх, сынап та карады соң
Чамалы түземлекне –
Аз да түгел, күп тә түгел,
Бердәнбер үземнекне.

Сукыр булды сөюләрем,
Адым саен ялгыштым,
Адым саен күрә торып,
Ялгышканга сабыштым.

Ел саен яндым, абындым,
Эзләдем, көттем инде.
Түзмәдем, эчтем хыянәт,
Югалдым, беттем инде.

1983

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»нан ай саен бер бүләк

1 ЯЗЫЛ!
2022 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!
30 майга кадәр газетага язылучылар арасында
ТАНДЫР һәм ӘФГАН КАЗАНЫ
уйнатабыз

6–16 июньгә кадәр газетага ташламалы бәядән язылып була!

П2435
җомга саны
423 сум 48 тиен
гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
942 сум 18 тиен
гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Май ае өчен квитанцияләр 2022 елның 8 июненә кадәр кабул ителә. Бүләк 9 июнь көнне уйнатылачак.

Акция 2022 елның 29 апреленнән башлап 17 июленә хәтле дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru
16+

Реклама

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕЛӘРЕ

Тандырда пешкән ризык тәмле һәм затлы!
Иң күп сайлау мөмкинлеге – «Тандыр 24» кибетендә.
Сезнең барлык сорауларыгызга җавап бирерләр.

«Тандыр 24», ТР, Казан шәһәре, Зәкиев урамы, 4 нче й., сул канат, 2 нче кат

тел.: +7-917-919-80-01

Реклама

Корыч казаннар, әфган казаннары, мангал, казаннар өчен мичләр. Безнең кибеттә табигатьтә ризык әзерләү өчен бөтен төр товарлар да бар.

тел.: +7-905-020-00-39

«Мир казанов 116», ТР, Казан шәһәре, Җиңү проспекты, 100 нче й., элмә тактасы – «ЭКОМАРКЕТ»

Реклама



Рәис Габдулла

20 май санында чыккан сканвордның җаваплары

Горизонталь буенча: ташлау, Сөмбел, башак, кырку, мур, Форма, Ивлин, ырам, арт, бригантина, Скотт, кая, Иншаков, аура, Нанкин, танк.

Вертикаль буенча: Тиса, кавырсын, шамбы, ки, бар, Ингода, ешкин, ат, куна, уклау, Ант, фырт, квант, мортира, ука, чума, Ядрин, рампа, Анк.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җаваплларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Казанда яшәүчеләр саны.

А) 1259173;
Б) 1900500;
В) 1300000.

2 Сталин вафат булган ел.

А) 1945;
Б) 1990;
В) 1953.

3 Рөстәм Яхин әсәре.

А) «Кояшларың белән кил син миңа»;
Б) «Дулкыннар, дулкыннар»;
В) «Туган тел».

4 СССРның беренче ясалма иярченен кайчан галәмгә җибәрәләр?

А) 1957;
Б) 1961;
В) 1988.

**5 «Әй мактыйлар мине, әй данлыйлар –
Портретлар хәтта көнләшә.
Кеше үзенең бөек икәнлеген
Каян белер иде үлмәсә?!»
Бу шигырь юлларының авторы кем?**

А) Саҗидә Сөләйманова;
Б) Рәдиф Гаташ;
В) Әнгам Атнабаев.

Җаваплар: 1) А; 2) В; 3) Б; 4) А; 5) В.

**Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16033 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 273

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+